ҖИҢҮ ХАКЫНА

«Чакыргач, бармый булмый», – ди егетләр

> 6

КИЛӘЧӘККӘ ИШЕК

КФУ галиме – укытучыларга бәйле вазгыять турында

> 16

ЛӘЙСӘН ФӘЙЗУЛЛИНА:

«Театрны ярату гомерлек була алмый»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 143 (28916) | Җомга | 30 сентябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

pixabay.com

ТАМАК ХАКЫ

АЗЫК-ТӨЛЕК БАЗАРЫНДА ВАЗГЫЯТЬ ТОТРЫКЛЫ

Узган атна алып килгән өлешчә мобилизация турындагы хәбәр халыкның бер өлешен кабаттан кибетләргә китерде. Капчык-капчык он, шикәр, ярма ташучылар күп булмаса да, азык-төлеккә мохтаҗлык башланмасмы, дип шикләнүчеләр бар. Кибетләр тирәсендә ыгы-зыгы тудырырлык сәбәп бармы? Без азык-төлек базарындагы гомуми вазгыятькә күзәтү ясадык.

> 5

Ишетми калмагыз

Эшләмәүче пенсионерларның пенсиясе киләсе елның 1 гыйнварыннан 4,8 процентка артачак. Россия Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы хәбәренә караганда, 2023 елда картлык буенча пенсиянең уртача күләме 21864 сумга җитәргә тиеш. «Эшләмәүчеләрнең пенсиясе быел 1 июньнән 10 процентка үсте. 1 гыйнвардан тагын 4,8 процентка артачак», – диелгән хәбәрдә. Социаль фондның киләсе елга тәгаенләнгән бюджетында 9,5 триллион сум салынган. Шуның чама белән 9 триллион сумы пенсия түләүгә тотылачак.

Агымдагы ел башына алынган мәгълүматларга караганда, эшләмәүчеләр пенсиясенең уртача күләме 19017 сум булган. Хәзер бу күрсәткеч – 20864 сум.

Татарстан Икътисад министрлыгы үзмәшгульләргә 700 мең сум акча эшләргә ярдәм иткән. Министрлык куптән түгел генә Казанда узган аш-су фестивалендә аларга үзләре җитештергән продукцияне сату өчен җиһазлы сәүдә урыннары биргән. «Кече һәм урта бизнес, шәхси эшмәкәрләргә ярдәм итү» илкүләм проекты кысасында узган фестивальдә барлыгы 89 үзмәшгуль катнашкан. Алар, аш-су, фермер продукциясеннән тыш, бизәнү-ясану әйберләре, уенчыклар, йорт кирәк-яраклары – барлыгы 700 мең сумлык товар саткан.

Үзмәшгульләргә үзләре эшләп чыгарган продукцияне сату буенча ярминкәләр ел дәвамында бөтен республика күләмендә үткәрелеп килә. Махсус ярминкәләрдә 1000гә якын кешегә товарларын сату мөмкинлеге бирелгән инде. Шул рәвешле алар барлыгы 17 миллион сумга якын акча эшләгән.

Татарстанда коронавирус йоктыручылар саны акрынлап кими. Соңгы тәүлектә республикада 635 кеше (алдагы тәүлектә – 637) чирләгән. Стопкоронавирус.рф порталы мәгълүматларына караганда, 61 сырхау хастаханәгә озатылган. Шул ук вакытта 1152 кеше тулысынча савыккан. Пандемия башланганнан бирле Татарстанда барлыгы 179322 кеше коронавирус кичергән. 2 млн 482548 кеше тулы вакцинация узган.

Гидрометеоүзәк фаразына караганда, атна ахырында һава температурасы +17, атна башында +18 градуска җитәчәк. Шимбә – 1 октябрьдә явым-төшем көтелми. Көндез +10…+15 градус, төнлә +3…+8 градус булачак. Якшәмбе – 2 октябрьдә күпчелек районнарда явым-төшем булыр дип фаразлана. Көндез термометрның терекөмеш баганасы +12…+17 градуска кадәр күтәреләчәк. Төнге сәгатьләрдә +4…+9 градус.

Синоптикларның башлангыч мәгълүматларына караганда, дүшәмбе – 3 октябрьдә яңгырлар явып үтәчәк. Сишәмбе – 4 октябрьдә урыны белән аз гына явым-төшем булачак. Көндез һава +13…+18 градуска кадәр җылыначак.

Бу атнада Гидрометеоүзәк кышның ничегрәк килүе турындагы фаразлары белән таныштырды. Декабрь аенда төлеклек уртача температураның – нормадан кимрәк, калган айларда нормада булуы көтелә.

Районнарда ни хәлләр?

Әлмәт

Шәһәрдә яшәүчеләр ДОСААФ базасында оештырылган гомуми хәрби әзерлек курсларын үтә ала. «Без халыкның махсус хәрби операцияләрдә катнашуга бәйле нинди дә булса төп күнекмәләрне үзләштерү белән кызыксынуын күрәбез. Өстәмә күнекмәләр тормышта да файдалы булырга мөмкин», – диде район башлыгы Тимур Нагуманов туры эфир вакытында. Кыр шартларында беренче медицина ярдәме күрсәтү курслары башланачак. Шулай ук тактик дәресләр һәм пилотсыз очу аппаратлары белән идарә итү буенча курслар оештыру планлаштырыла.
(«Әлмәт таңнары»)

Яшел Үзән

Узган җомгада шәһәрдә беренче хәйрия пункты эшли башлады, анда аз керемле кешеләр бушлай кайнар ризык белән туклана алачак. Проект «Нәфис» компанияләр төркеме, «Кеше приюты» үзәге һәм Казанның Кабан арты мәчете көче белән тормышка ашырыла. Шулай ук берничә коммерция компаниясе һәм иҗтимагый оешма ярдәм күрсәтә. Кайнар ризыкларны шәһәр кафеларының берсендә әзерлиләр, ризыкны туклану пунктына китерәләр.
Теләүчеләр павильонда көн саен 11.00дән 14.00 сәгатькә кадәр төшке аш ашый алачак. Шунысы мөһим: ризык бары тик хәләл продукциядән әзерләнә. «Мондый проектның беренчесен Яшел Үзәндә тормышка ашырабыз һәм соңгысы булмавына ышанам. Идел аръягы зонасында, Васильево, Осиново кебек зур торак пунктларда шундый объектлар кирәк», – ди район башлыгы Михаил Афанасьев.
(«Яшел Үзән»)

Түбән Кама

Шәһәрдән Украинадагы махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр өчен гуманитар ярдәм озаттылар. Кала халкы барлыгы өч тонна йөк җыйган. «Бу – безнең егетләр һәм ир-атларга җибәрергә теләгән игелек һәм җылылыкның бер кыйпылчыгы. Алар үзләрен өйдә көтүләрен тойсын иде. Алар – чын геройлар!» – ди шәһәр башлыгы урынбасары Марина Камелина. Түбән Кама районы башлыгы Рамил Муллин күрсәтмәсе белән, якын көннәрдә шәһәрнең төрле микрорайоннарында ярдәм җыю үзәкләре ачылачак.
(e-nkama.ru)

Азнакай

Район мәдәният йорты каршындагы мәйданда өченче тапкыр Самавыр бәйрәме уздырыла. «Алдагы ике елда ул – Татарстан Мәдәният министрлыгы, быел федераль грант буенча оештырылды. Күңел бәйрәме дияр идем, чөнки безнең халык шатлыгын да, кайгысын да самавыр янында якыннары белән бүлешкән», – ди район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Дамир Гыйләҗев.
(«Маяк»)

МАКСАТ ТА, ЮЛ ДА БЕР

«Татнефть»тә идарә итүнең яңа юлларын тәгаенләделәр, «Татнефтехиминвест-холдинг» оешмасында исә килеп туган шартларда файдалы булачак яңа проектлар барланды. Утырышларда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

tatarstan.ru

2025 елга кадәр идарә итүнең яңартылган стратегиясен карау, быелның сигез аенда бюджет үтәлеше нәтиҗәләре белән танышу, дүртенче кварталга бюджет раслау... Рөстәм Миңнеханов рәислегендә узган «Татнефть» ГАҖ Директорлар советы утырышы шул мәсьәләләргә багышланган иде.

Утырышта иң элек 2025 елга кадәр «Татнефть» төркеме җитәкчелегенә идарә итүнең яңартылган стратегиясе каралды. Аның кысасында хезмәткәрләр туплау, компенсация программаларын, ташламаларны һәм гарантияләрне көчәйтү, проектларны технологик үзгәрешләрне һәм яңа чакыруларны исәпкә алып гамәлгә ашыру күздә тотыла. Директорлар советы В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ инсайдер мәгълүматы турында»гы нигезләмәнең яңа редакциясен, мәгълүмат сәясәтенең яңа редакциясен дә раслады. Моннан тыш «Татнефть» оешмасының дивиденд сәясәте турында» нигезләмәсенә дә үзгәрешләр кертелде, оешманың дүртенче кварталга бюджеты расланды.

Татарстан Президенты катнашында узган икенче чара – «Татнефтехиминвест-холдинг» ААҖ Директорлар советының чираттагы утырышында исә берничә инновацион проект каралды. «Инновацион инжиниринг үзәге» КАБО генераль директоры Николай Колпаков, әйтик, үзәкнең импорт алмаштыру юнәлешендә башкарган һәм башкарачак эшләре турында сөйләде. Аерым алганда, үзәк «Газпром» оешмасының Ямал шельфындагы нефть һәм газ чыгару платформалары өчен краннарны импортлауны алмаштырырга ярдәм иткән. 2030 елга Россиядә 5 трлн сумлык сәнәгать продукциясе җитештерергә җыеналар бирелдә.

Инжиниринг һәм инновацияләргә ярдәм итү үзәге «Россиянең эре корпорацияләре ихтыяҗлары өчен технологик компанияләрне «үстерү» өчен грант программасы эшләтеп җибәргән. Бу хакта үзәкнең генераль директоры Павел Дворниченко сөйләде. «Үзебезнең компанияләр чит илдән кертелә торган товарларны алмаштырырлык яңа продуктлар эшләү һәм җитештерүләрне киңәйтү өчен 25–250 млн сум акча ала алачак», – ди ул.

Рөстәм Миңнеханов бу мәсьәләне эшләү өчен эшче төркем төзергә тәкъдим итте. Президент Татарстанның энергетика, нефть химиясе, нефть эшкәртү юнәлешендә бик күп проектларны тормышка ашыруын да билгеләп үтте.

– Бездә чит ил технологияләрен куллану бик киң таралган. Могҗизалар юк, без вариантлар эзлибез. Тиздән без барыбыз да ябылырга мөмкин. Безнең бурыч – илдәге вазгыятьне тамырдан үзгәртү, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Теләсә нинди шансны кулланачакбыз. Тормыш катлауланыр. Яңа санкцияләр пакеты да булачак. Йөрергә һәм сорарга түгел, ә үзебезгә эшләргә кирәк.

Утырыш барышында тәкъдим ителгән һәр проект үзенчәлекле. Мисал өчен, Мәскәүнең «ЭкоМир» фәнни-җитештерү берләшмәсе кеше өчен куркынычсыз уникаль биоцид һәм антисептик чаралар уйлап тапкан. Моннан тыш алар Удмуртиянең «Белкамнефть» компаниясе өчен сульфатны тозәтүче бактерияләрне бастыру һәм бораулау эремәләрен пластлы микроорганизмнардан саклау өчен реагентлар да эшләгән.

Йөрәк эше

Тормыш кыйммәтен чын мәгънәсендә аңлаган кешеләр җыелган урын. Россия кардиологларының Казанда узучы илкүләм конгрессын Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин шулай дип бәяләде. 2 октябрьгә кадәр дәвам итәчәк чарада илебезнең төрле почмакларыннан 5 меңләп белгеч катнаша. Өч көн дәвамында алар йөрәк-кан тамыры авыруларын кисәтү, дәвалауның заманча алымнары турында фикер алышып, тәҗрибә уртаклашачак.

Татарстанның парламент башлыгы сүзләре белән әйтсәк, аларның һәркайсы – үз куллары белән могҗиза тудыручы.

– Бүген бирегә тормыш кыйммәтен чын мәгънәсендә аңлаган кешеләр җыелды. Сез һәркайсыгыз үз кулларыгыз белән могҗиза тудырасыз. Кешеләргә чирне җиңәргә ярдәм итәсез, аларның сәламәтлеген кайтарып, өмет бүләк итәсез. Хезмәтегез, сайлаган юлыгыз һәм табиб бурычына тугры булуыгыз иң югары бәягә лаек, – диде Фәрит Мөхәммәтшин, конгресста катнашучыларны сәламләп.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның табибларга юлланган сәламләү хатында конгрессның өченче ел рәттән нәкъ менә Казанда узуы ассызыклана. «Казанда үтүче форум илнең фән-медицина өлкәсендәге мөһим вакыйгага әверелеп, кардиология тармагы өчен яңа үсеш мөмкинлекләре ачар, йөрәк-кан тамыры авыруларыннан интеккән кешеләргә югары технологияле махсуслашкан ярдәм күрсәтү мөмкинлекләрен арттырыр дип ышанам», – диелә Президент юллаган хатта.

Татарстан сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков фикеренчә, йөрәк сагында торучыларның очрашу урыны итеп нәкъ менә Казанның сайлануы юкка түгел. «Медицина фәне һәм бу өлкәдә белем бирү юнәлешендә бай традицияләр бар. Бездәге кардиология хезмәте дә иң танылган һәм хөрмәткә лаеклларның берсе санала», – диде министр.

Конгресста катнашкан Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш кардиологы Евгений Шляхто да республиканың бу юнәлештә алып барган хезмәтен «югары дәрәҗәдәге, үрнәк» дип бәяләде. Казаннан тыш, Чаллы, Түбән Кама, Чистайдагы кардиология хезмәте эшчәнлеге белән дә танышырга өлгергән ул.

Марат Садыйков сүзләренә караганда, республикада шушы юнәлештә хезмәт куючы белгечләр әзерләү эшенә аеруча зур игътибар бирелә. «Ел азагына кадәр барлык сырхауханәләрдә дә кардиологлар хезмәт күрсәтә башлаячак. Яхшы җиһаз сатып алу кыен түгел, анда эшләргә тәҗрибәле белгеч кирәк. Иң мөһиме әнә шул», – диде министр.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ӘНИ ДОГАСЫ

КАЗАННЫҢ СОВЕТ РАЙОНЫНДА ЯҢА МӘЧЕТ АЧЫЛДЫ

Башкалада мәчетләр саны тагын бергә артты. Совет районында «Рауза» мәчете ачылды. Июнь аенда тантаналы төстә аның манарасына ай куелган иде. Шулай итеп, Буа районының Яңа Тинчәле авылында туып-үскән Гайзатуллиннар әниләренең 90 яшьлек юбилеена менә шундый тарихи истәлек әзерләде.

tatarstan.ru

Мәчет ачу тантанасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм, мәчетнең ишеге изге максаттан ачып керелсен, гайбадәтханә халкыбызга хезмәт итсен, дигән теләген җиткерде. Эшләнеше, бизәлеше ягыннан да күңелгә нур өсти торган бина бу.

– Радик Рәүф улына аерым рәхмәт. Бик зур хезмәт. Матур, пөхтә мәчеттә рәхәтләнеп намаз укырга була. Бөтен шартлар бар. Барыгызга да тынычлык, исәнлек-саулык, сәламәтлек телим, – диде Президент.

«Ни өчен Казанда, Сеченов урамында?» – дип кызыксынучыларга Радик Гайзатуллинның җавабы мондый: «Бервакыт Алмаз хәзрәт белән берсеннән-берсе гүзәл, купкалты торак йортлар янынннан узып барабыз. Шунда хәзрәт: «Биредә халыкның күп яшәгәнлеге күренеп тора, мөселман кардәшләребезгә гыйбадәтханә бармы икән соң?» – дип сорап куйды. Менә шунда инде минем башка: «Биредә мәчет торгызсак, яхшы булыр иде», – дигән уй йөгерде. Уебыз Аллаһы Тәгаләнең «амин» дигән сәгатенә туры килде һәм әниенең, өйдәгеләрнең, туганнарның ризалыгын, хәер-фатихасын алып эшкә тотындык. Шулай да әнәй: «Бик зур эшкә алынасыз», – дигән иде. Аның сүзләрендә хаклык зур булды. Җирне рәсмиләштерү, бинаны проектлау, дизайн эшләре шактый ук мәшәкатьле иде, әмма ниятләү генә кирәк икән – ярдәм кулын сузучылар һәрвакыт табыла. Теләгебезне Президентыбыз Рөстәм Нургали улы да хуплады һәм ярдәменнән ташламады. Рәхмәт, бик зур рәхмәт!»

– «Рауза мәчете» нәкъ вакытында, нәкъ тиешле урында төзелде, – диде Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин. – Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйткән, «Кем Аллаһының ризалыгына өмет итеп мәчет кора, Аллаһы ул бәндәсенә шул мәчет мисалында җәннәттә йорт салып бирер», – дигән. Бик саваплы, изге гамәл бу.

Җәлил хәзрәт Фазлыев: «Мәчет никадәр сыйфатлы булса, җәннәт йорты да шулкадәр сыйфатлы булачак, – дигән фикерен җиткерде. – Ир кеше фани дөньяда нәрсәгә дә ирешә икән, бу – әнисе белән хатынының хәер-догасы. Килен кешелекле, мәрхәмәтле булмаса, эш – хана».

«Зөлфия ул безнең бәхетебезгә дөньяга килгән, – диде Радик Гайзатуллин. – Безнең гаилә корып яши башлавыбызга да утыз елдан артык, димәк, Зөлфиянең дә каенана белән яши башлавына шул гомер. Мин аларның сүзгә килгәннәрен, ялгышып кына булса да бер-берсенә төртмәле сүз әйткәннәрен бөтенләй хәтерләмим».

Гайзатуллиннар заманында Яңа Тинчәледә әтиләре Рәүф истәлегенә туган нигезләрендә мәчет торгызганнар иде инде. Авылда һәркөнне, намазга чакырып, азан яңгырый. Бабайлар, әбиләр, бала-чагалар пөхтә киенеп, намазга киләләр, әйе, иманлы авылның киләчәге ышанычлы. Яңа Тинчәле – гомумән, бик борынгы, тарихи авыл ул. Безнең якларда иң беренче гыйбадәтханә Казанда да, башка шәһәр-авылларда да түгел, нәкъ менә Яңа Тинчәледә Екатерина ІІнең рөхсәте белән төзелгән.

Мәчет ачылышына мөнәсәбәтле тантаналарда катнашкан дин әһелләре мәчетне төзеп кенә эш бетмәвенә, аның халыкка хезмәт итәргә тиешлегенә – гыйбадәт кылу, никахлар, дини бәйрәмнәр уздыру өчен уңай шартлар булдыру кирәклегенә басым ясадылар. Иншалла, биредә барлык нечкәлекләр, таләпләр искә алынган, халык канәгать һәм рәхмәтле булачак! «Рауза мәчете» озын гомерле булып, гөрләп эшләп торсын, азан тавышы еракларга ишетелеп, халык күңелендә иман ныклыгын арттыруга булышлык итсен!

Габделбәр РИЗВАНОВ

Дәүләт Советында

Дәүләт Советы Рәисе, «Бердәм Россия» партиясенең Татарстан төбәк бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин партия Рәисе Дмитрий Медведевның төбәк иҗтимагый кабул итү бүлмәсендә халыкны кабул итте.

Баулы районының Александровка авылында яшәүче Олеся Денисова үзләрендә балалар мәйданчыгын төзекләндерүдә һәм спорт залы төзүдә ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итте. Бу мәсьәләдә Олеся Денисова узган сайлау кампаниясе барышында да мөрәҗәгать иткән булган. «Республика Хөкүмәте раслаган юл картасына сезнең мөрәҗәгатегез кергән, – дип аңлатты Фәрит Мөхәммәтшин. – Үтәлү вакыты – 2024 ел. Сорауны үз контролемә алам». Парламент башлыгы шулай ук әлеге мәсьәләләр буенча район башлыгы белән дә фикер алышачагын әйтте. Мәрьям Самотуганина онығының язмышы борчый. Александр – ятим егет. Әбисе аны берүзе тәрбияләп үстергән. Әлегә ул вузда белем ала, шуңа эшли дә алмый. Пенсия килми башлагач, хәлләр тагын да мөшкелләнергә мөмкин. Фәрит Мөхәммәтшин бу хәлне игътибар белән өйрәнергә һәм ярдәм итү юлын табарга кушты.

***

Казанда «Минем цифрлы Татарстан» дигән беренче республика рәсемнәр конкурсына йомгаклар ясалды.

Әлеге бәйге Дәүләт Советының «Мәрхәмәт – Милосердие» берләшмәсе хатын-кыз депутатлары тарафыннан оештырылды, Татарстанның төрле районнарыннан 45 укучы җиңүче булды, тагын 26 катнашучы тамашачылар мәхәббәте призлары белән бүләкләнде. «Минемчә, мондый проектлар безне берләштерә, балаларыбызны цифрлаштыру шартларында үсәргә өйрәтә һәм ярдәм итә. Мондый чаралар аша балаларга үз хисләрен һәм фикерләрен белдерергә, үзләрен зур һәм әһәмиятле эшкә катнашы булган итеп тоярга мөмкинлек бирәбез», – диде Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин җиңүчеләрне котлаганда.

***

Казан (Идел буе) федераль университетында «Хокукка хокук» дип аталган халыкара юридик форум ачылды. Җыенны ачу тантанасында Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты һәм Президент Рөстәм Миңнехановның сәламләү сүзләрен ирештерде.

«Форумда күтәрелгән проблема бүген аеруча актуаль, хокук җәмгыятьнең һәм дәүләтнең таяну ноктасы булып тора. Татарстан һәрвакыт әлеге фикерне хуплап килде һәм хәзерге вакытта КФУга аны популярлаштыруда һәм алга алып баруда ярдәм итәргә әзер», – дигән Президент. Дәүләт Советы Рәисе дә үз чыгышында бүгенге актуаль мәсьәләләргә тукталды. «Безнең ил катлаулы чор кичерә, әмма Россия һәрвакыт үз позицияләрен саклау һәм үз мәнфәгатьләрен яклау юлларын тапты. Хәзер бөтен җәмгыятебезне берләштерергә, бердәмлекне күрсәтергә, ил җитәкчелеге кабул иткән карарны хупларга кирәк», – диде ул. Казан халыкара юридик форумы эше ике көн дәвам итәчәк. Икенче көнне белгечләр Иннополиста фикер алыша.

ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘБЕЗ

Айдар ШӘЙХИН

КВАРТИР / ФАТИР / КВАРТИРА

Квартира белән *квартир* – тиңдәш очраклар, әмма соңгысы сирәгрәк кулланыла. Ике вариант та сүзлекләрдә теркәлгән. Хәзер еш кына аларның аналогы буларак кулланыла торган *фатир* сүзенең хәле исә катлаулырак. Төп билгеләмәсенә күз салсак, бу сүзнең түләү шартларына килешеп урнашкан яшәү урыны булуын белә алабыз. Димәк, *фатир* – ул арендалана торган торак йорт, квартира, бүлмә яисә почмак. Шуңа күрә дә билгеле этимолог Рифкать Әхмәтьянов Татар теленең этимологик сүзлегендә «Фатир сүзен «квартир» мәгъ. куллану урынсыз вә сәвәтсез, чөнки бу ике сүзнең үз аерым мәгънәләре бар» дип әйтә.

Әмма тел беркайчан да урынында тормый. Сөйләмдә *квартира* урынына еш кына *фатир* сүзе кулланыла, димәк, аларны бер үк мәгънәдә дип карау очраклары (хаталы очраклар) арта. Тора-бара бу хата нормага әверелә ала. Билгеле, бу фаҗига түгел. Мондый үзгәреш хәерлерәк тә булырга мөмкин әле.

Фатир темасына кергәч, *снимать квартиру* сүзтезмәсен дә тәрҗемә итик. Аны *фатирга керергә, фатирда түләп яшәргә, фатирда түләп торырга* дип әйтергә була. Сөйләмне катлауландырырга теләсәгез, *квартира арендалыйм* дип тә әйтеп җибәрергә мөмкин. Әмма мондый тәрҗемәне һич тә киңәш итмәс идем.

ХИДӘЯТ / ҺИДАЯТЬ

Хидаят дигән формада язу дөрес түгел. Татар теленең гамәлдәге сүзлекләрендә теркәлгән вариантны үтәү мәҗбүри: һидаять. Бу алынма сүзнең башында Х хәрефе берничек тә тора алмый, аның оригиналында да гарәп имлясенең Һә хәрефе языла. Һидаять дигән язу очраклары да еш күренә, боларының мантыйгы аңлашылса да, сүзлектә кабул ителгән кагыйдәне үтәргә кирәк.

ПОСТАНОВКА / КУЕЛЫШ

Татарстан матбугатында театрларга бәйле яңалыклар бик еш басыла. Шөкер, мәдәният һәм сәнгать дөньясы даими үсештә. Театрларга заман алып килгән яңа формалар белән бергә, әлбәттә, телебезгә яңа төшенчәләр дә үтеп керә. Алар турында җентекләп язу әлегә актуаль түгел. Шулай да, еш кулланыла торган бер сүз хакында аңлатма бирмичә булмый. Рус телендә «показ кино», «показ спектакля» төшенчәләре бар. Гади генә итеп әйткәндә, спектакльне күрсәтү инде ул. Әмма матбугат хәбәрләрендә никтер гади генә булып чыкмый.

Мисал: Яңа театрда яңа спектакльнең показлары узачак. Күрсәтмәләр үзенчәлекле декорацияләрдә үтәчәк.

Әйе, кайвакыт показ, күрсәтмә, күрсәтү, хәтта күргәзмә дигән тәрҗемәләр дә очрый. Монда бары күрсәтү сүзе генә дөрес була ала, әмма аны да калька рәвешендә тәрҗемә итеп кулланырга ярамый. Спектакльнең күрсәтүе булачак дигән җөмлә дөрес була алмый.

Яңа театрда яңа спектакль күрсәтеләчәк. Спектакль үзенчәлекле декорацияләр белән күрсәтеләчәк һ.б.

Театрга бәйле башка төшенчә – постановка. Аны, традициягә таянып, постановка дип тә, куелыш дип тә тәрҗемә итәргә мөмкин. Яңа лингвистик «ноу-хау»лар уйлап табасы юк.

Әйтеп кенә бактым

Антистереотип

Марат КӘБИРОВ

Безнең белән президент та, ваграк түрәләр дә, хәтта хатын (ир) галиҗәнаплары да түгел, ә гади генә стереотиплар идарә итә. Без тирә-якка күз салабыз да – чынбарлыкны түгел, үзебез күрергә теләгән нәрсәләрне дә түгел, ә стереотипларны күрәбез, шуларны ишетәбез...

Иң күп таралган стереотип – сары чәчле кызлар сантыйрак була. Бу, әлбәттә, дөрес түгел инде. Гомумән, чәч белән акылның бөтенләй бәйләнеше юк. Хиллари Клинтон, Кристиан Лагард, Ангела Меркель – моның якты мисалы. Дөрес түгел, әмма киң таралган. Шуңа күрә сары чәчлеләрнең чынлап та сантыйлары моңа ышанып, чәчен карага манып йөри. Андыйлар күп...

Хатын-кыз колагы белән ярата, диләр. Ә ир-ат йөрәгенә юл – ашказаны аша. Ә саңгырау хатын-кыз? Ярый... Менә сез йөргән кызыгызга гел матур сүзләр генә сөйләп торыгыз әле. Бернинди ресторанга, һич югы кафега да чакырмагыз. Яратамы ул моны? Шиш! Һәм дөрес эшли. Ну, колагына эленгән токмач белән туклана алмый бит инде ул. Хатының булса да шул. Син берни дә дәшмәскә мөмкинсең, әмма суыткычың тулы булырга тиеш. Гомумән, хатын-кыз йөрәгенә юл – суыткыч... ашказаны аша. Ләкин бу – бердәнбер юл түгел... Ачның ачуы яман, дигән сүз дә дөреслеккә туры килми. Ачның ачуын басар өчен аны туйдыру да җитә. Ә менә тук кеше ачуланса, монда инде нишләргә дә белеп булмый.

Стереотиплар гомер буе озата. Ул «тиеш»ләрнең чиге-чамасы юк.

Бала «бишле»гә укырга тиеш, диләр. Бала укырга тиеш. «Бишле»гә укуы аның башлырак, акыллырак булуын аңлатмый. Бу нибары аның йогынтыга тизрәк бирелүчән, яраклашучан икәнен генә аңлата. Иң өметлесе – «өчле»гә укыган бала. Димәк, ул алтын урталыкны таба белә: балачакның да рәхәтен күрә, укуын да бөтенләй онытмый. Белем запасын соңыннан да тулыландырырга мөмкин, ә бала чакны кире кайтарып булмый. Сабый чагында балалык рәхәтен күреп туймаган кеше гомер буена балалыктан арына алмый.

Мәктәпне тәмамлагач, кеше югары белем алырга тиеш. Югары белем, кызыл диплом – яхшы, әлбәттә. Ә бүген иң киң таралган һөнәрләр – сатучы, каравылчы, таксист... Моның өчен диплом мотлак түгел. Ләкин кызыл диплом да кешенең яхшы белгеч яки акыллы кеше икәнен билгеләми. Ул бары тик: «Бу кеше бер катыргы өчен үзенең яшьлеген корбан итәргә сәләтле», – дигәнне генә аңлата. Диагнозның бер төре, кыскасы.

Кеше эшләргә тиеш. Монысы – стереотипларның иң коточкычы. Әгәр эшлисе килми икән, теләге юк икән – кеше беркайда да эшләргә тиеш түгел. Теләге булганнар гына эшләсен. Эшлисе килмәгәннәргә пособие билгеләргә кирәк. Чөнки эшләргә теләмәгән килеш кайдадыр эшләп йөргән кешедән дә куркынычрак зат юк. Менә күз алдына китерегез. Врач. Хирург. Аның бу хастаханәдә бер минут та эшлисе килми. Һәм ул сезгә операция ясарга тиеш... Ә кемнеңдер бик эшлисе килә, тик алмыйлар – буш урын юк, чөнки аның урынында теге хирург эшли...

Эшләгән өчен акча түләргә кирәк. Безнең илдә бу стереотип акрынлап юкка чыгып килә – акча түләргә бик ашыкмыйлар. Җитәкчеләребез түбәндәге мантыйк буенча гамәл йөртә. «Эшләгән өчен акча түләргә? Кирәкми! Бушка эшләргә дә риза түгел икән, димәк, ул үз һөнәрен яратмый. Мондый кешедән беркайчан да рәт чыкмаячак, аны эш нәтиҗәсе түгел, ә акча гына кызыксындыра. Әгәр кеше үз һөнәрен ярата икән, ул бушка эшләргә дә әзер. Бушка эшләргә дә риза икән, ник аңа акча түләргә?»

Кеше гаилә корырга тиеш. Бала тудырырга... Билгеле бер яшькә җиту белән кешене: «Кайчан өйләнәсең инде?», «Кайчан кияүгә чыгасың?» – дип аптырата башлыйлар. Хәтта ул бик булдыксыз, юньсез кеше булса да, шулай диләр. Хәтта әти-әнисе шулай ди. «Балам, гаилә кора күрмә, кемнедер бәхетсез итәсең бит», – диюче юк. Ана – бөек исем... Ә ул аналарның кайберсе бары тик абортка соңлаган өчен генә бөек булып йөри. Бөеклекләре, прәмә, һәйкәл куярлык. Олы кеше акыллы һәм тәҗрибәле була. Ә тәҗрибә – сантыйлык нәтиҗәсе.

Һәм сез мине дә стереотип буенча кабул итәсез. Ахырда җилле генә бер мәгънә чыгарып куюымны көтәсез. Ләкин мәгънәсез язмалар да була. Бу нәкъ шул очрак, чөнки стереотипларга кизәнүдән дә мәгънәсезрәк нәрсә юк.

ТИШЕК ТОРБА СӘЯСӘТЕ

Дөньядагы хәлләр, дәүләтләр арасында мөнәсәбәтләр, кызганыч, торган саен хәвефлерәк була бара. Үткән тәүлекләрдә хәвефләргә тагын бер хәвеф өстәлде: башта «Төньяк агым – 2» торбасында басым кинәт кими башлады, аннан соң «Төньяк агым – 1»дә шул ук хәл кабатланды. Өч юан торба – миллиардлаган кубометр газны Европага кудырырга тиешле үткәргечләр бер-бер артлы сафтан чыктылар. Технологик катастрофаларга безнең колаклар күнеккән инде, шуңа гади обывательөчен «агым»нарның эштән чыгуы куркыныч берни дә аңлатмый. Әмма сүз гадәти технологик һәлакәт турында бармый, зур сәясәтнең куркыныч конфликтка китерергә ихтимал булган драмасы уйнала. Эш гади генә түгел, ә бик нечкә интригалар кора һәм дәһшәтле нәтиҗәләргә китерә ала торган дәрәҗәдә сискәндерерлек. Хәзер сәясәтчеләр менә шул интригаларны корып азапланалар да инде. Торбалар тишелү белән бер вакытта диярлек Болгария Тышкы эшләр министрлыгы үз гражданнарына кичекмәстән Россиядән китәргә кушты. Польша дипломатиясе дә нәкъ шундый ук белдерү ясады. Бераз гына соңгарак калып АКШ илчелеге дә америкалыларга кичекмәстән Россияне ташлап китәргә киңәш итте. Дипломатик вәкиллекнең: «Если вы хотите уехать из России, вам следует как можно скорее самостоятельно принять меры», – дигән сүзләрен укыйбыз «Коммерсантъ»тан. Дөрес, американнар моны ике ил гражданлыгы булганнарны да мобилизацияләргә мөмкин дип аңлаталар. Әмма киңәш барлык америкалыларга да кагыла. Бу – хәтәр. Эшне зурга җибәрергә телиләр.

Хәзер торбаларның тишелүенә әйләнеп кайтыйк. Ни өчен бу авария куркыныч. Беркем дә үлмәде, яраланучылар да юк. Тишекләр халыкара суларда – Даниянең икътисади зонасы янында ук пәйда булды. Башта «Төньяк агым – 2» авариясе мәгълүм булгач, өр-яңа торбаны да юньләп тоташтыра алмаганнар дигән уй күңелгә килде. Башка торбалардан да SOS хәбәре алынганнан соң гына шик калмады: сүз диверсия турында бара. Торбаларның хуҗасы – Nord Stream AG компаниясе («Газпром»ныкы), торбаларның ватылуы тиңе булмаган дәрәҗәдә, дип белдерде. Аларны кайчан эшли башларлык итеп ремонтлаячакларын да хуҗалар әйтми. Агымдагы вазгыятьтә Россия торбаларны ремонтлый алмый да, чөнки кирәкле җиһазлар юк, андый җиһазларны ала да алмый: санкцияләр юл куймый. Бу торбалар баштан ук бик җәнҗаллы булды. «Төньяк агым – 2» бер кубометр да газ кудырмаган килеш тик торды. Торба черен эштән чыкмасын өчен, аңа техник газ тутырып куйдылар. Хәзер шул газ суга ага. Бу юллар язылганда, 2 миллиард долларлык газ акты, диделәр инде. Тагын берничә көн агачак икән әле. «Төньяк агым – 1» шулай ук сәясәт коралына әйләнде. Мәскәү аны да «компрессорлар ватык» дигән сылтау белән туктатты. Европалылар моны шантаж дип кабул иттеләр. Кремльнең максаты Европа державаларын Украинага ярдәмне туктатырга мәҗбүр итү, Киевка басым ясап, аны Россия куйган шартларда сөйләшүләр өстәле янына утырту иде. Әмма Көнбатыш башкалалар бу басымга бирешмәделәр. «Төньяк агым – 1» аз күләмдә генә газ кудыруны дәвам итәргә кереште. Ә менә Украина аша үтүче торбадан газ даими агып торды. Мәскәү Киев белән булган килешүне газ күләмнәре буенча төгәл үтәде, әмма транспортлаган өчен акча гына түләмәде. Банк системасына салынган санкцияләр акча түләргә мөмкинлек бирми, дип аклады. Украина шул мәсьәләдә Мәскәүне арбитраж судына бирде. Соңгы көннәрдә бу суд тирәсендә дә конфликт бара. Кремль, судның алдан ук Россиягә каршы карар чыгарасы билгеле дип, Украинадан процессны туктатуны таләп итә, газ кудыруны бөтенләй туктату белән яный. Янау тормышка ашырылса, Европа авыр хәлдә калачак. Газны бары тик «Төрек агымы» аша гына алачак. Күләме бик кечкенә булуы аңлашыла инде. Европада болай да энергетик хәл катлаулы. Кем кемне дигән сорау кабыргасы белән куела. Мәскәүдә киеренкелекне яңа югарылыкка күтәрүдән курыкмыйлар, ва-банкка баралар.

Хәзер торбаны кем шартлатты дигән сорауга җавап эзләп карыйк. Бу бик мөһим. Яшәү-үлем мәсьәләсе дәрәҗәсендә мөһим дип ассызыклыйк. Шартлау булуына берәү дә шикләнми. Швед сейсмоүзәге үзәге «Төньяк агым»нар районында куәтле су асты шартлаулары булуын хәбәр итте. Швециянең Диңгез идарәсе корабларга шартлау булган урынны 9 километр ераклыкта әйләнеп узарга кушты, хәтта самолетларга да мең метрдан да түбәнгәрәк төшмәскә куашып итеаде. Дания һәм Гренландиянең Геологик хезмәте алынган сигналлар җир тетрәү нәтиҗәсендә түгел, шартлау нәтиҗәсендә дигән рәсми фикер әйтте. Швециянең Упсаль университеты сейсмологлары икенче шартлауның 100 килограмм тротил шартлавына тиң булуын әйттеләр.

Германиянең икътисад министры Роберт Хабек тишекләрнең махсус һөҗүм нәтиҗәсендә пәйда булуын раслады. Еврокомиссия башлыгы Урсула фон дер Ляйен шулай ук газның суга агуын «саботаж» дип бәяләде һәм Европаның энергетик инфраструктурасын алдан уйлап бозган өчен «хәлиткеч җавап» бирү белән янады. Украина чиновниклары ачыктан-ачык эшне Россиягә ягарга маташалар, «Европага һөҗүм итте» дигән тезисны алга чыгаралар. Киевның максаты ачык: НАТО белән Россияне турыдан-туры чәкештерү. Украина позициясенең бер йомшак ягы бар: дәлилләр юк. Путин сүзчесе Песков та «саботаж мөмкинлеге»н кире какмаулары турында әйтте.

Торбаларны нииндидер аерым террорчы төркемнәр шартлата алмый. Су астында эшли торган роботлар һәм шундый роботларны йөртә торган махсус су асты көймәләре кирәк. Андый куәтләр бик сирәк дәүләтләрдә генә бар. «Российская газета» Берлинда да Россияне гаепләүчеләр барлыгын яза. «Польша в лице своего замминистра иностранных дел Марчина Пшидача, вполне ожидаемо поспешила указать на Россию», – дигән юлларны да укыйбыз хөкүмәт газетасыннан. Немец матбугатында АКШка төртеп күрсәтүчеләр дә бар икән, чөнки, бердән, океан арты державасының моңа техник мөмкинлекләре бар, икенчедән, Байден февраль башында ук: «Россия Украинага бәреп керсә, берниндн дә «Төньяк агым»нар булмаячак», – дип янаган. Украинадан шикләнүчеләргә, Киевның мондый диверсия ясарга техник мөмкинлеге юк, дигән җавап бирәләр. АКШ ягы европалыларга гаепләне табуда булышырга вәгъдә бирә. Менә шунда иң хәвефле урынга килеп җитәбез дә инде: Көнбатышта Россияне гаепләсәләр (алар Мәскәүнең бу эш өчен мотивлары бар дип саныйлар), эш зурга китәргә мөмкин. «Ватаным Татарстан» хәбәрчесе хәзерге мизгелдә НАТО – Россия коралды конфликтына ук барып җитмәсләр дип уйлый, чөнки тимерне кызуында сукмады беркем дә. Әмма Украинага корал белән ярдәмне көчәйтү өчен акларлык сылтау итә алалар. Вашингтон инде хәзер үк «Хаймерс»ларның яңа партиясен Украинага җибәрү карарын кабул итте. Германиянең Украинадагы илчесе Анка Фельдгузен: «Украина Бундесверның үзендә дә булмаган яңа һава һөҗүменә каршы тору системалары алачак», – диде. Сүз кырык километр радиуста 20 километрга кадәр биеклектә очучы объектларны бәреп төшерерлек куәткә ия IRIS-T системалары турында бара. Аның ярдәмендә самолет-вертолетларны да, канатлы ракеталарны да, реактив артиллерия снарядларын да, дроннарны да бәреп төшерергә була. АКШ та 16 NASAMS вәгъдә итәләр. Болары – югары технологияле норвег зенит-ракета комплекслары. 2 километрдан 40 километрга кадәр радиуста аталар, 30 метрдан алып 16 километрга кадәр биеклектәге ракеталарны юк итәргә сәләтлеләр. Мәсәлән, Вашингтонны һава һөҗүменнән NASAMSлар саклый.

Американнар украиннарга референдум нәтиҗәсендә Россиягә кушылган төбәкләргә үз кораллары белән атарга рөхсәт иттеләр. Бу уңайдан Россиянең Вашингтондагы илчесе Анатолий Антонов: «Андый рөхсәт Киевны куркыныч сызыкка якынайта һәм АКШны конфликтның бер ягына әйләндерә», – дип белдерде. Путинның каршы як Россия төбәкләренә һөҗүм итсә, атом коралы кулланылачагы турындагы сүзләре (аеруча, бу блеф түгел дигән кисәтүе) искә төшә дә, каз тәне чыга. Торба тишеге безне куркыныч хәлгә куя бит әле. Алдагы көннәрдә тагын берничә сылтау табылып, эш зурга китмәс дип кем әйтә ала. «...дело не экономике, а в политике», – ди бу уңайдан «Российская газета» да.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Зөһрә САДЫЙКОВА

ТАМАК ХАКЫ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Ыгы-зыгы юк

– Узган атнада күршем шикәр бәясе 100 сумнан артып киткән дигәч, шунда ук кибетләргә бардым. Дөрес, андый бәягә шикәр күрмәдем. Бер кибеттән – 64, икенчесеннән 68 сумга алып кайттым. Ул көнне шактый кибеттә булдым мин. Киштәләр шактый бушаганнарын да очратырга туры килде. Тик шикәрдән кала башка бөтен төр продукция дә җитәрлек иде. Аңлавымча, шикәрне дә киштәләргә тезеп кенә өлгермәгәннәр иде, – ди Казанда яшәүче Алсу Хәкимова.

Узган атнада шуңа охшаш хәлләр районнарда да күзәтелгән булып чыкты. Мәсәлән, безгә килеп ирешкән хәбәрләр буенча, Сабада халык он, шикәр, макарон, дөге, карабодай һәм башка ярмаларны складлардан капчыклап ташыган.

Башкала кибетләрендәге хәлләрне күреп бәяләр өчен берничәсенә үзебез дә кереп чыктык. Күзәтү өчен Әмирхан, Ямашев проспектларындагы «Магнит», «Пятерочка», Ершов урамындагы «Бәхетле» кибетләрен сайладык.

Бер генә кибеттә дә чиратта торган, ыгы-зыгы тудырган халыкны күрмәдек. Тик «Пятерочка» кибете сатучысы Марат Аксанов әйтүенчә, соңгы берничә көндә кибеттә шикәр беткән.

– Тоз, он, ярмалар – барысы да бар. Ә менә шикәр бөтенләй юк. Сәбәпләрен әйтә алмыйм, узган атнада халык шактый күпләп алды. Тик март ае белән чагыштырганда, сорау ул дәрәҗәдә зур булмады. Җомга көнне шикәрнең бәясе 59 сум иде. Аңа кадәр 64–67 сум булды, – диде ул.

Ни гаҗәп, шикәрне без «Магнит» кибетендә дә таба алмадык.

– Дүрт көн китермиләр инде аны. Кичә, машина юк, дип әйткәннәр иде. Бүген хәбәр булмады әле, – диде безгә менеджер. – Соңгы тапкыр ничә сумнан сатылган булгандыр, әйтә алмыйм, чөнки хәзер аларның бәяләрен истә калдырып була торган түгел. Ике көн саен алышына. Ялгышмасам, 59 сум да, 64 сум да булды. Элек мин «Бәхетле» кибетендә эшләдем. Анда бәяләр бу кадәр үк тотрыксыз түгел иде. Ике ай тирәсе шул бер бәя саклана иде. Хәзер бер нәрсәне дә истә калдыра торган түгел, без инде хәтердә сакларга тырышмыйбыз да. Безнең кибеттә соңгы айларда товар бәяләре чамадан тыш артты дип әйтеп булмый. Берничә сумга я күтәрелә, я төшә. Узган атнада да, монысында да халыкның күпләп товар алуы сизелмәде.

Берничә кибеттә таба алмаган шикәрне «Бәхетле»дә таптык барыбер. Биредә аның бер килограммын 84 сумнан саталар иде.

Димәк, кибетләр тирәсендә ыгы-зыгы юк, азык-төлек җитәрлек. Узган атнада, мобилизация турындагы хәбәрдән соң кузгалыш бераз булса да, тиз арада сүрелгән. Шушы ук фикерне Казанның Тихорецкая урамындагы күпләп сату складларында эшләүче менеджер Александр Билалов та куәтләде.

– Берара халык капчыклап он, шикәр, ярмалар сатып алды, тик озакка бармады ул. Бернигә дә кытлык юк. Сорау зур булгач, ике көн киштәләрне тутырырга гына өлгермәдек. Бүген инде элеккечә эшлибез, – диде ул.

Кайбыч районы Мәлки авылы кулланучылар җәмгыяте идарәсе рәисе Салават Халиков та районда азык-төлек белән тәэмин итүдә берниндди дә проблема юкыгын әйтте.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Хәтта язын бер җирләрдә күзәтелгән ыгы-зыгы да булмады бездә. Кибетләрдә барлык төр ризык та бар. Халык үз көе белән килеп ала. Шикәре дә, оны да, ярмалары да җитәрлек. Бездә халык ярмаларны кибеттән гомумән сирәк ала. Агрофирмалар хезмәт хакы исәбенә бирә. Кибеттән алган очракта да, күпләп ташымыйлар. Бәяләр дә бер урында тора. Шикәргә бәя, киресенчә, төште, – диде ул.

Шулай да кайбер кибетләрдә ни сәбәпле шикәр юк? Әлеге сорауны республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына юлладык.

– Дөресен әйткәндә, мондый проблема барлыгы турында беренче тапкыр ишетәбез. Кибетләргә анализ ясарбыз, тикшерербез һәм шуннан соң сезгә хәбәр итәрбез. Сатып алучылар киштәләрне бушаткач, кибет хезмәткәрләре аларны кабат тутырырга өлгерми. Кайвакыт киштәләрнең буш булуы шуңа гына бәйле. Бәлки монда да складлардан кайтарып өлгермәгәннәрдер. Әлеге вакытта бер генә продукциягә дә кытлык юк. Республика азык-төлек белән җитәрлек тәэмин ителгән. Төп продукция – ит, сөт, шикәр, ярмалар, яшелчә, кош ите, он – барысы да бар, – диделәр безгә министрлыкта.

Казан федераль университетының Идарә итү, икътисад һәм финанс институты профессоры Игорь Кох фикеренчә, халыкта «массага кушылу» күренеше көчле.

– Халык дөрес булмаган хәбәрне я вазгыятьне белеп бетермичә, яки хәлне тагын да кискенләштерер өчен махсус тарата. Шуңа күрә коткыга бирелүнең бер мәгънәсе дә юк. Әлеге вакытта сату челтәрләрендәге вазгыять үзгәрер өчен бер сәбәп тә юк, – дип ышандырды ул.

Кесә ягы такыр

Быел Россия базарында дөнья хәлләре, яңалыклар фонында бик зур ыгы-зыгы булган иде инде. Хәтерләсәгез, 24 февральдән соң, халык товарлар кытлыгыннан һәм бәяләр артудан куркып, беренче чиратта кирәкле товарларны әрҗә-әрҗә, капчык-капчык ташыды. Кибет киштәләре вакытлыча бушап торды да, складлардан кабат кайтарып тутырдылар. Кыскасы, шулкадәр ыгы-зыгы булса да, азык-төлек базарына авырлык килмәде, халык он, ярма, шикәргә тилмермәде. Хәер, ул вакытта кешеләрнең җыеп калган запаслары әле дә җитәрлектер. Узган вакыйгалардан сабак алучылар да шактый булган, күрәсең. Мобилизация турындагы хәбәрләрдән соң бераз күтәрелеп, тиз арада сүрелгән ыгы-зыгының сәбәпләрен шулай дип тә аңлатырга мөмкин.

Белгечләр арасында, соңгы хәбәрләр, киресенчә, халыкны сакчыл булырга өйрәтергә мөмкин, дип санаучылар да бар. «Кешеләр тора-бара гаиләләренә югалту, кайгы килү мөмкинлеген аңлаячаклар һәм гаилә бюджетын уңга-сулга таратмыйча, булган акчаларын саклап калырга тырышачак. Кемдер инде илдән чыгып качты, кемдер башка илгә китү ягын караячак, кемдер баласын армиядән алып калу хәстәрен күрәчәк, кемдер гаиләнең төп туендыручысын югалтудан куркып, итәк-чабуын җыячак», – дип китерә Россия аналитикларының фикерен РБК басмасы.

Хәер, аналитик күзәтү нәтиҗәләре быелның августында ук инде Россиядә яшәүчеләрнең кием һәм техника алудан тыелып торып, күбрәк тамак ягын кайгыртуын күрсәткән. Мәсәлән, илдә техника һәм электроника сатудан кергән акча 18 процентка кимегән, ә кулланучылар 15 процентка кимрәк товар сатып алган. Уртача чек 9,9 мең сумны тәшкил иткән. Бу исә узган ел белән чагыштырганда, 11 процентка кимрәк. Үзәк банк белгечләре мондый күренешне россиялеләрнең бурычлылары һәм акчаны исраф итмәскә тырышулары белән бәйләп аңлаткан.

Финанс белгече Сирин Зарипов та, быел россиялеләрнең, шул исәптән татарстанлыларның да, сатып алу мөмкинлеге сизелерлек кимегәнлеген әйтте.

– Моның беренче сәбәбе – керемнәрнең артмавы. Икенчесе – зур инфляция, чөнки күп кенә җитештерүчеләр үз товарларын Россиядән алып чыгып китте һәм логистик бәйләнешләр үзгәреп, эшмәкәрләргә озынрак юл сайларга туры килде. Бу да товарның ахыргы бәясенә йогынты ясый, – диде ул.

Белгеч фикеренчә, илдәге соңгы вакыйгалар, ягъни мобилизация дә халыкның икътисади хәленә йогынты ясамыйча калмаячак.

– Мобилизация күпчелек халык өчен шок булды, алар аңа әзер түгел иде. Беренче көннәрдә үк кешеләр банкоматларга йөгерде, акчаларын ала башлады. Ләкин бу күренеш тиз арада сүрелде, хәзер андый хәл күзәтелми. Шулай ук күп кешенең илне калдырып чыгып китүен дә күреп, ишетеп торабыз. Алар арасында мобилизациягә яраклы ир-атлар күп. Дөрес, гаиләләр белән китүчеләр дә бар. Аларга чит илдә нинди дә булса акчага яшәргә кирәк бит. Шунлыктан кемдер фатирын арендага бирәчәк яки сатачак. Шул сәбәпле бездә фатирга тәкъдим артып, милеккә бәяләр бер урында торырга яки аска тәгәрәргә мөмкин. Моннан тыш, халыкның «кара көн»нәргә әзерләнә башлавы да бар. Андыйлар гадәттә капчык-капчык он, ярма артыннан кибеткә йөгерәчәк, – ди Сирин Зарипов.

Бәяләр

Азык-төлек базарына күзәтү ясарга алынганбыз икән инде, бәяләргә дә күз салу урынлы булыр. Росстат бәяләрнең 18 атна тотрыклы торганнан соң, узган атнада кайбер төр товарларга бәяләр артуын әйтә. Беренче чиратта, кыяр һәм помидор кыйммәтләнгән. Аның каравы соңгы көннәрдә шикәргә бәя төшү күзәтелә. Ул быелның июне белән чагыштырганда 4 процентка кимеде. Ләкин узган елның декабре белән чагыштырганда, шикәр 34 процентка кыйммәтләнеп, бәясе арткан продуктлар исемлегендә лидер булып тора.

* (сумнарда)

Продукция атамасы	19.09.22	26.09.22	Бер атнада булган үзгәреш	Бер айда булган үзгәреш	Ел башыннан үзгәреш	Ике айда булган үзгәреш	Узган ел белән чагыштырганда үзгәреш
Сыер ите (сөяксез иттән башка)	485,1	484,8	-0,2	-1,1	81,0	1,8	103,8
Тавык (ботыннан тыш)	154,3	155,6	1,4	-1,8	- 6	-6,4	-1,1
Йомырка	60,9	61,3	0,4	1,7	-19,1	0,1	4,5
Атланмай	666,1	666,2	-0,8	- 4,2	86,4	-1,2	143,0
Шикәр	70,1	69,0	-1,1	-1.0	16,3	-0,5	21,4
Он	45,9	45,4	-0,5	-1,1	4,2	-3,2	10,1
Карабодай	100,9	96,8	-45,1	-6,8	-0,6	-12,5	11,1

Мәгълүматлар республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгыннан алынды

Кирәк йөккә әйләнмәсен

Чамасын белеп кенә. Өлешчә мобилизация игълан ителеп, хәрби операция зонасына баручылар да, аларның туганнары да бу кагыйдәне яхшы белергә тиеш. Бигрәк тә юлга әзерләнгәндә. Коралын һәм башкасын тиешле урында кайгыртырлар. Аннан тыш көн итәр өчен хәрбигә нәрсәләр кирәк? Бу хакта безгә 15 елдан артык контракт буенча хезмәт итүче, махсус хәрби операциядә беренче көннәрдән үк катнашкан Рамил (исеме үзгәртелде) сөйләде.

Мобилизацияләнүче үзе белән нәрсә алырга тиеш?

Соңгы көннәрдә социаль челтәрләр киңәшләр белән тулды. Нәрсә генә юк анда. Барысын да ала башласаң, йөзләгән мең сум акча кирәк анда. Әле эзли башласаң, таба да алмыйсың. Шуңа күрә, беренчедән, баш белән уйларга кирәк. Икенчедән, нәрсә кирәклеген урынга барып җиткәч кеше үзе аңлый башлый.

Барысына да киңәш итәрлек беренче һәм төп кагыйдә – үзең белән җылы кием алырга! Әйтик, термо эчке кием. 2 комплект алсагыз яхшы. Актив һәм пассив төрләргә бүленә алар. Беренчесе актив хәрәкәт иткәндә кулланылса, икенчесе әллә ни хәрәкәтләнмәгәндә, тик торганда кирәк. Йон оекбаш алырга кирәк. Өч пар актив, икесе – пассив хәрәкәтләнү өчен. Өч пар эчке кием алырга киңәш итәм. Моннан тыш флис тукымадан кофта, ул җиңел һәм коры кием санала. Кышкы ак маскхалат (камуфляж костюм) булса да бик яхшы. Җил һәм дымнан саклый торган костюм булса да әйбәт. Җылы һәм һава үткәрүчәнлеге яхшы саналган тукымадан (SoftShell технологиясе) эшләнгән куртка да ярап куяр. Башны да җылыда тотасын онытмаска!

Аяк киеменә килгәндә, резин итекнең эчке яктан оеклысын алырга киңәш итәр идем. Берцовка урынына исә махсус тукымадан (Gore-Tex технологиясе дип атала) ясалган ботинка алырга мөмкин. Алар дымны сеңдерми. Димәк, аяк корыда була. Ә бу гаять мөһим!

Башка кирәк-яракларга килгәндә, кием-салымнан тыш җылы, әмма җиңел йокы капчыгы (спальник) кирәк булыр. Шәхси әйберләр турында әйткәндә, кул астында запас батарейка (8 данә), мөмкин кадәр күбрәк дымлы салфетка, телефон өчен пауэрбанк (тиз арада зарядка җыйдыру өчен махсус җайланма) булса әйбәт.

Сәламәтлекне һәркем үзенчә кайгырта инде. Даруларны да – кемнең кай төше авырта, шуның дәвасын үзе белән алырга онытмасын. Әмма төп дарулар һәркемдә булырга тиеш.

Газ горелкасы, турист савыт-саба җыелмасы да һәр кешенең үзенеке булса яхшы. Болар шулай ук мөһим кирәк-яраклар! Маңгайга киеп йөри торган сыйфатлы фонарь (гадәти фонарь дә ярый), пычак алырга кирәк дип өстәр идем. Ниндидер вак-төяк кирәк-яраклар белән букчаларын тутырмасыннар иде.

Шәхесне раслаучы документларны һәм банк карталарын онытмаска кирәк. Акчаның артыгы булмаячак. Телефонның исә төймәлесе генә рөхсәт ителә.

Якыннар белән сөйләшү

Өйдәгеләр белән бу хакта ничек сөйләшәсең инде? Иң мөһиме – чама хисен саклау. Артык хисләнеп китү бирәүгә дә файдага түгел. Ватанны сакларга кирәк, ир-ат булуымны дәлилләргә кирәк дип аңлатырга тырышыгыз. Ничек тә тынычландыру җаен кайгыртырга кирәк инде. Хисләргә бирелмәскә, өйгә исән-имин әйләнеп кайтуың турында күбрәк уйларга, күткәннәрен аңларга!

Шәхси аптечка

- ✓Турникет (яраланган очракта кирәк)
- ✓Дарулар (сызлануган, югары температурадан, агуланудан)
- ✓Антисептик
- ✓Бинт
- ✓Шприц
- ✓Пластырь
- ✓Медицина кайчысы
- ✓Пантенол

КАЙТЫРГА ДИП КИТӘЛӘР

Илдар Мөхәммәтҗанов

Татарстанда Мобилизация комиссиясе көндәлек эшен дәвам итә. Утырыш нәтиҗәләре буенча оператив рәвештә барлык мәгълүмат Татарстан Президентына җиткерелә. Кичә Рөстәм Миңнеханов Хөкүмәткә республикадан мобилизацияләнгән һәр кешене кирәкле дарулар җыелмасы булган аптечка һәм келәмле йокы капчыклары белән тәэмин итәргә кушты.

Фаяз абыйга 53 яшь. Хәрби офицер, яшьлегендә Иркутскида хезмәт иткән. 1994 елда тыныч тормышка кайтып, эшмәкәрлек эшенә алынган. Шарлар сату, бәйрәмнәрне бизәү белән шөгыльләнгән. Кыскасы, кешеләргә шатлык өләшкән. «Азнакайда мин белмәгән кеше юк, балалар «Шарик бабай» дип йөртәләр», – ди ул, елмаеп. Быел исә кулына корал алган...

Үз теләге белән махсус хәрби операциягә чыгып киткән Фаяз абыйның хатыны, кызы, 2 һәм 6 айлык оныклары бар. Улы контракт буенча хезмәт итә, махсус операциядә катнаша.

– Моннан 30 ел элек Киевта хәрби училище тәмамлаган идем, 9 майда шунда парад белән узасы килде. Операциядән кайткач, мобилизация буенча чакырып алдылар. Хәзер биредә егетләргә кабат хәрбиләр сафына басарга ярдәм итәм. Тәҗрибә белән уртаклашам. Бирегә килеп, башкаларга булышу – минем өчен намус эше. Барысы да исән-сау кайтсын дип тырышабыз, – дип сөйли ул. – Якташларыма, Азнакайга сәлам! Безгә җылы оекбашлар бәйләп җибәргән әниләргә, абиләргә аерым рәхмәт. Әлбәттә, кайтачакбыз, безне көтегез. Җиңү безнеке булачак.

Дамир абый да – Азнакай районыннан. Өлешчә мобилизация буенча чакырылганчы мәктәптә укытучы булып эшләгән. Бер айдан 55 яшен тутырырга әзерләнә. Ике улының берсе хәзерге вакытта армия хезмәтендә.

– Чакырганнар икән, димәк, без кирәк. Безнең әтиләр-бабайлар да илне яклаган, димәк, безгә дә шул язган, – ди ул.

Өлкәннәрдән аермалы буларак, яшьләр сүзгә саранрак. Салават – Балык Бистәсе районының Яңа Арыш авылыннан. Армия хезмәтеннән 6 ел элек кайткан, чакыру кәгазе килеп төшкәнче төзелештә эшләп йөргән.

– Өйдә хатын озатып калды. Алар елый, мин тынычландырырга тырышам инде. Дөресен әйткәндә, повестка киләсен көткән идем. Чакыргач, бармый булмый. Мин барысына да әзер, – ди ул.

Фаяз һәм Дамир абыйлар, Салават белән без «Казан Экспо» халыкара ярминкә үзәгендә таныштык. Мобилизациягә эләккән кешеләрне җыю буенча Казандагы өч урынның берсе бу. Район-шәһәрләрдән чакырылган егетләрне башта Казан танк училищесына алып киләләр. Аннары җыю пунктларына юллыйлар. Биредә аларны белгечлекләренә карап подразделениеләргә бүләләр, хәрби хезмәтнең ни икәнен исләренә төшерәләр. 1 октябрьдә хәрби әзерлек башлана.

– Яшермим, кайчандыр армиядә хезмәт итеп кайткан, аннары гадәти тормышка ияләшкән 30–40 яшьлек кешене кабат сафка бастыру җиңел түгел. Ни дисәң дә, 18 яшьлекләр белән эшләү җиңелрәк. Әмма барысы да диярлек тормышындагы үзгәрешне аңлап кабул итә. Икенче көнне үк яңа шартларга ияләшә башлыйлар. Әлбәттә, мондый кинәт үзгәрешләр беркемгә дә җиңел бирелми. Шуңа күрә ярдәм итәргә тырышабыз. Туганнары белән очрашу мөмкинлеге дә бар, – ди заманында Һава десанты гаскәрләрендә хезмәт иткән, аннары ялга чыгып, Әлмәттә эшләп алган, хәзер исә мобилизация буенча кабат Ватанны сакларга чакырылган подполковник.

Биредә егетләргә кулдан килгәнчә барлык шартларны булдырырга тырышканнар. Өч тапкыр ашаталар. Ризык туклану комбинатында әзерләнә. Кичә иртән, мәсәлән, аларга йомырка, май ягылган бутерброд, итле ботка, чәй-каһвә, печенье тәкъдим иткәннәр. Мобилизацияләнгән егетләр без килгәндә салат, тавык ите турап салынган дөгеле аш, икенчегә ит белән бәрәңге ашап утыра иде. Казанның азык-төлек һәм социаль туклану департаменты генераль директоры Рима Мөхәммәтшина әйтүенчә, ризыкны хәрбиләрнең туклану таләпләрен истә тотып әзерлиләр.

Ашау гына түгел, башкасын да кайгыртканнар. «Казан Экспо»да Татарстанның Юстиция министрлыгы юридик төркемнәре дә эшли. Анда егетләрнең хокук мәсьәләсендә булган сорауларына тиз арада җавап табарга тырышалар. Адвокат һәм нотариус белән киңәшләшергә мөмкин. Министр урынбасары Мөхәррәм Ибәтов әйтүенчә, беренче көнне сорауларның күбесе суд приставлары эшчәнлегенә кагылган. Шуңа күрә бирегә Суд приставлары федераль хезмәте вәкилләрен дә чакырып китергәннәр. Социаль ярдәм, хәрби хезмәткә чакырылучылар өчен кредит түләү тәртибе буенча сораулар җитәрлек.

Мобилизацияләнгән егетләр өчен «Казан Экспо»да медицина пункты да ачылган. Биредә вакцинация пункты да булдыру күздә тотыла. Берничә көн элек Президент Рөстәм Миңнеханов күчмә мунча алып килергә кушты. Алып килгәннәр, кичә төш вакытында ярминкәләр үзәгендә мунча ягып яталар иде.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

МОБИЛИЗАЦИЯ БУЕНЧА СОРАУЛАР БУЛСА...

★Россия Оборона министрлыгының «кайнар линия»се: 8 (800) 100-77-07; 8 (495) 498-43-54; 8 (495) 498-34-46.
★122 номеры буенча «кайнар линия».
★«Объясняем.РФ» сайты.

Урман – агачсыз, дөнья нужасыз булмас. Ил-көн вакыйгалары кешелекне кабат тетрәнергә, битараф булмаска мәҗбүр итте. Хисләрне тыя алмауның юньлегә илтмәвен дә онытып җибәрдек бугай. Моның турында белгечләр дә кисәтә. Соңгы вакыйгаларга карап, йөрәк сызлаган вакытта, салкын акылны ничек сакларга? Рухи, физик һәм матди халәтне ничек кайгыртырга? Бу һәм башка сорауларга җавап табарга тырыштык.

pixabay.com

ЗЫЯН ИТМӘ!

КИЕРЕНКЕ ЧОРДА ҖАНГА ДА, КЕСӘГӘ ДӘ САК КАРАШ КИРӘК

Күңел халәте

Практик психолог **Зөһрә КӘРИМОВА**, кешенең яхшыга өметләнүе, таянырлык эчке кыйбласы булган очракта ил-көн кичергән тетрәнүне җиңү җиңелрәк, ди. Белгечтән тынычлану ысуллары, башны караңгы уйлар биләгәндә дә үз-үзеңне кайгыртуны онытмау әһәмияте турында сораштык.

:: Сер түгел, сентябрь вакыйгалары күпләргә зур стресс алып килде. Үз-үзеңне ничек кулга алырга соң?

– Беребез өчен дә җиңел вазгыять түгел. Һавада да, урамда да, кибеттә дә, сәүдә үзәкләрендә дә – бөтен җирдә коткы, курку, төшенкелек һәм борчылу җиле исә. Мондый вакытта үз-үзеңне ничек кулга алырга? Минем беренче һәм төп киңәшем шул: рухи яктан тотрыксызрак, гадәти вакытта да бик борчылучан кешеләр газеталарны азрак укысын, телевизорны сүндерсен, көнен социаль челтәрләрдә уздырмасын иде. Болар барысы да аларның эчке халәтләрен тагын да катлауландыра гына. Икенче киңәш – якын кешеләр белән күбрәк булырга, онытылырга, яраткан эш, шөгыльгә вакыт бүләргә. Спорт та булыша. Элеккеге рухи халәтне янәдән кайтарырга тырышырга кирәк.

:: Социаль челтәрләр, бер яктан, безгә файдалы мәгълүмат бирә, икенче яктан, артыгын борчылырга да дучар итә. Чама хисен ничек сакларга соң?

– Һәркем өчен билгеле бер чик бар. Ул норманы кеше үзе билгели инде. Әйтик, социаль челтәрләрне бөтенләй карамаска киңәш ителгән кешеләр бар. Социаль челтәрләр турында онытып тору өчен үзеңне йорт-җир тирәсендәге эшләргә багышларга була. Гомумән, үз тормышың белән яшәүдән кала башка чара юк. Син тышкы хәлләргә йогынты ясый алмыйсың, әмма бу хәлләр синең эчке халәтеңне җимерергә сәләтле. Йогынты ясап булмагач, ситуацияне җибәрергә кирәк. Организмга озылган нерв системасы, төшенкелек кирәк түгел!

:: Туганнар, дуслар, хезмәттәшләр белән ничек аралашырга? Телдә гел бер сүз бит...

– Сезнең белән уртаклаша торган мәгълүматны иләк аша уздырырга! Тегеләр бу хакта сөйләшү сезгә ошамый яисә бу хакта ишетәсе килми икән, турыдан әйтегез. «Бу хакта соңрак сөйләшик», «Миңа әлегә бу кызык түгел» диярга мөмкин бит. Күпләрнең андый темаларны күтәрерлек рухи ресурсы да юк. Без барыбер билгесезлектә, ә билгесезлек куркыта. Кешеләрнең төп бурычы – үзләре өчен куркынычсызлык тудыру. «Янымда – якыннарым, мин сәламәт, мин исән-сау», – дип кабатлагыз. Бу – бик зур нигъмәт, бик күпләрдә булмаган байлык!

:: Стресс кичергәндә кешенең организмында нинди үзгәрешләр күзәтелә?

– Монда да барысы да кешенең үзенә бәйле. Әйтик, кемдер кача, кемдер коткыга бирелә, «катып кала» дибез, күпләр «Ник? Ни өчен?» дигән сораулар яудыра. Төшенкелеккә чумганнар үз проблемаларын ашап «баса» башлый. Бу организмда кортизол дигән гормон барлыкка килүгә бәйле. Ул үзе белән йокысызлык, өстәмә авырлык алып килә. Хатын-кызлар өчен бигрәк тә кыен. Аларның борчылу хисе көннән-көн арта. Гүзәл затлар куркынычсызлыгын югалтудан бик курка.

Күпләр стресс дип, авызын йөгәнли алмый дидек бит. Мондый очракта суыткычка түгел, белгечкә мөрәҗәгать итәргә кирәк дип саныйм. Психологка барырга, сәбәбен бергәләп ачыкларга. Канәгатьләнү хисен, тынычлануны ризыктан түгел, башка нәрсәләрдән табарга өйрәнергә. Сер түгел, гадәттә, эшсез ятканда гел ашыйсы килә. Шуңа да үзеңне нинди дә булса шөгыль белән мавыктырып торырга кирәк. «Минем чынлап та ашыйсым киләме?» дип үзеңә сорау бирергә.

:: Төп ихтыяҗлар – ашау-эчү, йокы, физик хәрәкәт турында да онытмау мөһимдер?

– Саф һавада йөрү, ашау, йоклау – болар барысы да безгә көч, энергия, ресурс бирә торган кирәкле ихтыяҗлар. Алар турында онытсак, тормыш итүдән дә туктыйбыз дигән сүз бит. Хәзер килеп туган шартларда яшәргә өйрәнү – барыбызның да бурычы. Хәрәкәт, вакытында йокларга яту, дөрес итеп туклану – үзеңне кайгыртуның бер ысулы.

Матди як

Ил-көндәге үзгәрешләр акча тирәсендә дә шау-шу уята. Кесә ягын кайгыртыр чак. Хәзерге чорда акчаны нишләтергә? Бизнеслы кешеләргә нишләргә? Кеше хәсрәтеннән табыш алучы кырыгалдарлардан ничек сакланырга? Финанс белгече **Ләйсән ХАЛИКОВА** бу һәм башка сорауларга ачыклык кертте.

:: Сакларгамы, җыяргамы, тотаргамы – акчаны нишләтергә?

– Актуальлеген югалтмый торган киңәшем: финанс мендәрен булдыру. Ул-бу була калса, безнең кулда запас акча булырга тиеш. Әйтик, гаиләле кешегә яшәр өчен кимендә ярты еллык акча тупларга кирәк. Вазгыять киеренке чорда бу аеруча мөһим. Валютадан күпләр котылырга тырыша. Әмма мин болай итү бик үк дөрес түгел дип саныйм. Диверсификация (акчаны төрле валютада саклау. – **Авт.**) әле дә мөһим. Мондый киеренке чорда бигрәк тә бер төрле валютага гына салынып яшәргә киңәш ителми. Иң төп киңәш – бөтен булган акчаны банкта сакламагыз. Бер өлеше үзегездә торса яхшы. Йә сейфта, йә башка урында. Ул акчаны теләсә кайсы мизгелдә алырлык булсын.

:: Ил икътисадына мобилизация ничек йогынты ясар?

– Барыбыз да аңлый – федераль бюджетның зур өлеше дәүләт оборонасы заказына китәргә мөмкин. Шунысы белән икътисадка тәэсир итәчәк.

:: Бизнес вәкилләренә хәзерге катлаулы чорда нишләргә? Аларга да итәк-чабуларын җыярга туры килер инде...

– Аларга да җиңел түгел. Бигрәк тә кече бизнес вәкилләренә, авыл хуҗалыгы тармагындагы мәшгульләргә. Әйтик, заводта 10–20 мең кеше эшли, ди. Шул заводтан 10–20 кеше китсә, әллә ни йогынты ясамаска да мөмкин. Ә инде бизнесның кече субъектларына кыенга туры киләчәк. Аларда хезмәткәрләр саны күп булмаска мөмкин, берничәсе генә хәрби хезмәткә алынса да, сизеләчәк. Эшләргә кеше аз кала. Андый очракта нишлисең инде? Йә читтән кеше эзлисең, йә хатын-кызларга мөрәҗәгать итәсең. Авылларда бу җәһәттән хәлләр кыенрак та. Болай да авылга кайтып эшләргә теләгән кешеләр бихисап түгел иде бит... Бизнес вәкилләренең дә нинди тармакта булуы мөһим бит әле. Кайберләре мондый катлаулы чорда, киресенчә, үсеш алачак, файда китерәчәк. Әйтик, халыкны тукландырырга, ашатырга кирәк. Чит илдән әйберләр керми. Мөмкинлеге булганнар эшен дәвам итәчәк. Бирешмәскә кирәк.

:: Ыгы-зыгылы чорда мошенниклар да активлаша бит әле. Аларның корбаны булмас өчен нишләргә?

– Аның корбаны булмас өчен, иң элек паниканы кырыйга куярга кирәк. Вазгыятьне салкын акыл, аек баш белән бәяләргә. Нинди мәгълүматка тап буласы икән, иң элек аның дөреслеген тикшерергә кирәк. Таныш-белешләрдән, юристлардан сорашырга. «Икенче фикер» дигән төшенчә бар. Бу кагыйдәне тормышыбызда куллана башласак иде. Мәсәлән, нииндер сорау туды, ди. Бу белгеч белән дә сөйләшеп кара, икенчесенекен дә белеш.

Мошенниклар олы яшьтәге апаларга шалтыратып, ир туганнарыгызны мобилизацияләнүдән коткарабыз, дип ялганларга да мөмкин. Моның өчен зур сумма сорыйлар, әлбәттә. Әхлакый яктан караганда да, бу – оятсызлык! Бик түбән гамәл. Болай да киеренке вазгыятьтә, җиңел корбан эзләп, шуннан акча эшләргә... Моны аңлатырлык сүз дә юк. Кеше дә теләсә нәрсәгә әзер инде. Мошенниклар шул йомшак ягыбыздан файдалана. Уяу булырга кирәк.

:: Коткыга бирелеп, кирәкмәгән әйберләр сатып алудан тыелып торырга кирәктер?

– Запас акча булдырырга өлгермисең, гел нидер килеп чыга. Шуңа күрә хәзер ихтыяҗ булмаган әйберләр сатып алыр чак түгел. Әлбәттә, запас ризык булдыру ярый. Әмма кибетне басып алу дигән сүз түгел әле бу! Чама хисен югалтмыйча гына. Коткыга бирелеп, еларга кирәкми. Яшәүне дәвам итәргә! Без төшенкелеккә бирелгән саен, начаррак. Негатив белән яшәү җиңел түгел.

P.S. Белгечләр сүзенә өстәмә итеп, шуны әйтәсе килә: иң көчле корал – сүз. Аның нииндиен кулланасыз бит. Бәгырьләрне катырырлык, күңелләрне өшетерлекләрен әйтмик. Дөнья үз кучәренә бер әйләнеп кайткач, сүздән алган яраларны ямаштырырга язмасын. Бер-беребезне саклыйк! Кадерлик! Иң катлаулы чорда да кешене яхшыга өметләнү яшәткән. Яңашадагыларга шул өмет чаткысын бирик.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

3 октябрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «КИТӘМ, ДИМӘ» 12+
10.00, 23.00 «ГОСПОДА – ТОВАРИЩИ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «ШУЛЕР». (Татар телендә) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00, 03.30 «Әдәби хәзинә» 6+
19.00, 20.00, 00.15 «Таяну ноктасы» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Соотечественники» 12+
01.05 «Ватандашлар» 12+
01.30 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
01.45 «Если хочешь быть здоровым» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.05 «Кояш яшергән малай». Татарстанның халык артисты Нуретдин Нәҗмиев турында телеочерк 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.20 «СИНА КАЙТАМ» 12+
19.10, 21.25, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
22.20 «Татар теле дәресләре» 6+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 В честь 350-летия Петра Великого. «СОБОР» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «ЧАЙКИ» 12+
22.20 «Вечер» 12+
01.00 «МОРОЗОВА» 16+
02.55 «СРОЧНО В НОМЕР!-2» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 Смешанные единоборства. UFC. Х. Нурмагомедов против К. Макгрегора. Трансляция из США 16+
07.00, 10.00, 12.55, 15.30, 18.35 Новости
07.05, 18.40, 21.50 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 15.35 Специальный репортаж 12+
10.25 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00 Бокс. Чемпионат России. Мужчины. Прямая трансляция из Читы
15.55 «Громко». Прямой эфир
16.55 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. «Нева» (Санкт-Петербург) – ЦСКА. Прямая трансляция
19.00 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. ЦСКА – СКА (Санкт-Петербург). Прямая трансляция
22.40 Тотальный футбол 12+
23.10 Смешанные единоборства. UFC. Маккензи Дёрн против Ян Сяонянь. Вячеслав Борщев против Майка Дэвиса. Трансляция из США 16+
00.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Локомотив-Кубань» (Краснодар) – МБА (Москва) 0+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «ЛИХАЧ» (S) 16+
22.00, 00.00 «БАЛАБОЛ» (S) 16+
00.20 Олег Тактаров, Алексей Чадов, Анна Старшенбаум. «МЁРТВ НА 99%» (S) 16+
03.35 Остросюжетный сериал «МЕНТ В ЗАКОНЕ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.45 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.15 «Давай разведёмся!» 16+
10.10 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча». «Узлы» 16+
13.45 «Знахарка» 16+
14.15 «Верну любимого» 16+
14.50 «СТАРУШКИ В БЕГАХ – 2». 1-я – 4-я серии 16+
19.00 «С КЕМ ПОВЕДЁШЬСЯ...». 1-я – 4-я серии 16+
22.45 «Порча». «Дублёрша». «Замриумри» 16+
23.50 «Знахарка» 16+
00.25 «Верну любимого» 16+
00.55 «Понять. Простить» 16+
01.50 «Тест на отцовство» 16+
03.30 «Давай разведёмся!» 16+
04.20 «ЖЕНСКАЯ КОНСУЛЬТАЦИЯ» 16+
05.10 «6 кадров» 16+
05.20 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «ВЗРЫВ НА РАССВЕТЕ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 23.25 «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ГРАНИЦА». «МЫ НАШ, МЫ НОВЫЙ...» 1-я серия 12+
10.55 «Москва фронту». Док. сериал 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «РУССКИЕ АМАЗОНКИ». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «На грани возможного. История НПП «Звезда» имени академика Г.И. Северина». Док. сериал. Фильм 1-й. Премьера! 16+
19.40 «Загадки века». Док. сериал. «Станислав Петров. Он спас мир от ядерной войны» 12+
22.55 «Между тем» 12+
00.50 «ИНСПЕКТОР УГОЛОВНОГО РОЗЫСКА» 12+
02.20 «БЕСПОКОЙНОЕ ХОЗЯЙСТВО» 12+
03.45 «Оружие Победы». Док. сериал 12+
03.55 «РУССКИЕ АМАЗОНКИ» 16+

4 октябрь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.00, Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «КИТӘМ, ДИМӘ» 12+
10.00, 23.00 «ГОСПОДА – ТОВАРИЩИ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ШУЛЕР». (Татар телендә) 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Казаннан – казанга» 12+
18.00 «Таяну ноктасы» 16+
19.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Автомобилист». Прямая трансляция 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Бехтерев. координаты души 12+
00.45 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
01.00 «Если хочешь быть здоровым» 12+
01.15 «Татар әдәбияты дәресләре» 6+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
15.30 «Ватандашлар» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20 «СИНА КАЙТАМ» 12+
19.10, 21.25, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
22.20 «Татар теле дәресләре» 6+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «СОБОР» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. «ЧАЙКИ» 12+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 «МОРОЗОВА» 16+
02.55 Ярослав Бойко, Ольга Погодина. «СРОЧНО В НОМЕР!-2» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 10.00, 12.55, 15.30, 19.00 Новости
07.05, 15.55, 19.05, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 15.35 Спец. репортаж 12+
10.25 Еврофутбол. Обзор 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00 Бокс. Чемпионат России. Мужчины. Прямая трансляция из Читы
16.55 Футбол. ФОНБЕТ Кубок России. «СтавропольАгроСоюз» (Невинномысск) – «Нефтехимик» (Нижнекамск). Прямая трансляция
19.30 Футбол. Лига чемпионов. «Бавария» (Германия) – «Виктория» (Чехия). Прямая трансляция
21.45 Футбол. Лига чемпионов. «Интер» (Италия) – «Барселона» (Испания). Прямая трансляция
00.55 Футбол. Лига чемпионов. «Аякс» (Нидерланды) – «Наполи» (Италия) 0+
02.55 Новости 0+
03.00 Бокс. Чемпионат России. Мужчины. Трансляция из Читы 0+
05.05 «Правила игры» 12+
05.30 «Наши иностранцы» 12+

НТВ

04.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «ЛИХАЧ» (S) 16+
22.00, 00.00 «БАЛАБОЛ» (S) 16+
00.20 «МЁРТВ НА 99%» (S) 16+
02.55 «Их нравы» 0+
03.20 МЕНТ В ЗАКОНЕ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.05 «Давай разведёмся!» 16+
10.05 «Тест на отцовство» 16+
12.10 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча». «Сын охотника» 16+
13.45 «Знахарка» 16+
14.15 «Верну любимого» 16+
14.50 «СТАРУШКИ В БЕГАХ – 2». 5-я – 8-я серии 16+
19.00 «С КЕМ ПОВЕДЁШЬСЯ...» 5-я – 8-я серии 16+
22.45 «Порча». Без ног». «Корыстный треугольник» 16+
23.50 «Знахарка» 16+
00.25 «Верну любимого» 16+
00.55 «Понять. Простить» 16+
01.50 «Тест на отцовство» 16+
03.30 «Давай разведёмся!» 16+
04.20 «ЖЕНСКАЯ КОНСУЛЬТАЦИЯ» 16+
05.10 «6 кадров» 16+
05.45 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

04.40 «РУССКИЕ АМАЗОНКИ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 23.25 «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ГРАНИЦА». «МЫ НАШ, МЫ НОВЫЙ...» 2-я серия 12+
10.55 «4 октября – День Космических войск (день запуска первого спутника)». Док. фильм 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «РУССКИЕ АМАЗОНКИ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.15 «Спецрепортаж» 16+
18.50 «На грани возможного. История НПП «Звезда» имени академика Г.И. Северина». Док. сериал. Фильм 2-й 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» 12+
00.50 «БУДНИ УГОЛОВНОГО РОЗЫСКА» 12+
02.15 «СВИНАРКА И ПАСТУХ» 12+
03.40 «Победоносцы». Док. сериал. Черняховский И.Д. 16+
03.55 «РУССКИЕ АМАЗОНКИ» 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 3–9 ОКТЯБРЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Ярдәмгә тиенү, бурычлардан котылу чоры. Күңелдәге шик-шөбһәләрне алып ташлагыз: барысы да әйбәт булачак. Атна ахырында күңелле яңалыклар ишетеләчәк.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Эчке сиземләвегез дөп-дөрес адымга этәрәчәк. Эштә барысы да әйбәт булачак: җитәкчегез, нәтиҗәле эшләвегезне күреп, ниһаять, үзегезне җитди бәяләячәк. Ләкин гадәттәгедән күбрәк эшләргә туры киләчәк.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Атна урталарында гаиләгездә берникадәр кытыршылык барлыкка килергә мөмкин. Көнчелекне йөгәнләгез, теләсә нәрсә уйлап йөрмәгез. Тавыш чыгуны шулай итеп кенә булдырмый калачаксыз.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Бер белмәгән кешеләр белән аралашу күңелегезгә җиңеллек, зур өмет-ышанычлар китерер. Уйламаган җирдән үтә файдалы мәгълүматлар килеп төшәр. Атна ахырында әйбәт кенә керемгә өметләнеп булыр.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Атна башында матди хәлегез яхшырыр. Керемегез гаилә һәм йорт өчен кирәкле әйберләр сатып алуга да, башкасына да җитәр. Үзегезне начар итеп күрсәтергә теләүчеләр гайбәт сүзләр таратырга мөмкин. Иң яхшысы – аларны күрмәмешкә һәм ишетмәмешкә салышу.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Һава торышының көзге көйсезлеге салкын тидерү, вируслы чирләр белән яный. Шуңа күрә җылырак киенеп йөрергә кирәк. Атна ахырында хәерле хәбәрләр ишетерсез.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Акчагызга игътибарлырак булыгыз: мошенниклар «кармагы»на эләгү куркынычы бар. Бу көннәрдә күңелегездә гаять зур өметләр уятырдай шәп яңалыклар ишетерсез. Хезмәттәшегезнең киңәшен тотып уңарсыз.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Гаилә мәшәкатьләре байтак вакытыгызны алыр. Әмма борчыласы юк: барысы да – күңелле мәшәкатьләр. Бер танышыгыз белән күрешеп сөйләшү күңелегезгә тынычлык иңдерер.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Атна уртасында үзегезгә яңа эш тәкъдим итәргә мөмкиннәр. Ашыкмагыз, моның гаиләдәге мөнәсәбәтләргә зыян салу-салмавы турында әйбәтләп уйлагыз. Яхшы яңалыклар көтегез.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Якыннарыгызның дәгъвасын аңларга тырышыгыз: алар сезгә бары тик яхшылык кына тели. Әйткән сүзләрегез өчен җавап бирергә һәм өстегезгә бурычлар алырга әзер торыгыз. Керемнәрнең артуына өметләндерердәй хәбәрләр ишетерсез.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Серләрегезне хәтта иң якын дусларыгызга да чишмәгез: уңайсыз хәлгә куюлары бар. Бурычка биреп торудан шикләнмәгез – яхшылыгыгыз үзегезгә йөзе белән әйләнеп кайтачак. Атна ахырында бер хыялыгыз тормышка ашачак.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Тормышыгызның әйбәт якка үзгәрүенә сәбәп чыгар. Эштә дә – барысы да ал да гөл. Хезмәт хакыгыз артыр, абруегыз тагын да үсәр. Сәбәбе бик саллы шул...

Покупаем пух-перо (новые гусиные), старые перины и подушки.
Также производим обмен на постельные принадлежности **с выездом на дом.**
Телефоны: 8927-430-50-15, 8905-047-69-72.
реклама

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КАЙНАР ЧӘЙ «БҮЛӘГЕ»

Мәкерле дошман. Белгечләр елдан-ел тамыр җәйгән яман шеш авыруын шулай дип атый. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы китергән саннардан аңлашылганча, Җир шарында ел саен яман шештән 9 миллион чамасы кешенең гомере өзелә. Бу нәрсә белән аңлатыла? Яман чирне алдан кисәтеп буламы?

Табиб-онколог, проктолог, хирург Тимур КАСЫЙМОВ шул сорауларыбызга ачыклык кертте.

:: Бүген республикада яшәүче һәр 35 кешенең берсендә яман шеш ачыклана. Бу саннардан чәчләр үрә торырлык...

– Кызганыч, яман шеш очраклары бүген, дөрестән дә, артканнан-арта бара. Бу, иң беренче чиратта, туклануга салкын каравыбызга бәйле. Химия, пистицидлардан торган зарарлы ризык ашау бүген күпләребез өчен гадәти күренешкә әверелде. Элегрәк кеше организмда билгеле бер үзгәреш күзәтелүгә үк табибка мөрәҗәгать итә иде. Бүген күпләр бу эшне дә ахыргача сузып йөри. Интернеттан укып, үзенә диагноз куя, үз белдекелеге белән дәвалана алар. Вакыт табып тикшеренгәндә инде еш кына чир азган була. Яман шешнең җәмгыятебездә ныклап тамыр җәюенә нигездә әнә шулар сәбәпче.

ЯМАН ШЕШТӘН САКЛАНУ ӨЧЕН ТАБИБ КИҢӘШЛӘРЕ

✓Нәселендә яман шештән интеккән кешеләргә даими рәвештә табибка күренеп торырга, вакытында диспансеризация узарга кирәк.

✓Организмда теге яки бу үзгәреш күзәтелгән очракта да кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итү хәерле. Бу теләсә кайсы чирне алдан кисәтергә яки башлангыч чорда ачыкларга ярдәм итәчәк.

✓Туклану да игътибардан читтә калмасын. Дөрес тукланырга, авызга кабар алдыннан иң элек һәр ризыкның составын яхшылап өйрәнергә, файдалы булса гына ашарга кирәк.

✓Кайнар чәй, кайнар ризык белән мавыгу да хәерлегә түгел.

✓Тәндә пәйда булган бер генә тап, тимгел, шешне дә игътибарсыз калдырырга ярамый. Вакытында табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

:: Яман шеш барлыгын нинди билгеләр буенча чамаларга була?

– Яман шеш үзен сиздермичә, бернинди билгеләрсез генә дә узарга мөмкин. Аның аермачык билгеләре, гадәттә, чирнең соңгы стадияләрендә, чир аза башлаганда гына беленә башлый. Әгәр кешенең аппетиты югалса, ул кисәк кенә ябыга башласа, хәлсезләнсә, тиз арыса, кисәк кенә гемоглобины төшсә, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Сүз уңаеннан, тире, күкрәк, юан эчәк яман шеше – бүген республика халкы арасында әлеге яман чирнең аеруча киң таралган төрләре.

:: Сезгә, барыннан да бигрәк, ашказаны, эчәклек яман шешенә каршы көрәшергә туры килә.

– Алар да, иң беренче чиратта, кешенең дөрес тукланмавы, фастфуд кебек зарарлы ризыклар белән мавыгуы аркасында килеп чыга. Эч катудан тилмергән кешедә дә эчәклек яман шеше еш күзәтелә. Гадәттә, андый чакта гомер буе эч катудан тилмергән кешедә кисәк кенә диарея башлана, аның гемоглобины түбәнәя. Колоноскопия ясагач, эчәклекләрендә яман шеш икәнлеге ачыклана. Бу яман чир нәселдән дә күчәргә мөмкин. Шуңа күрә нәселендә шушы төр яман шештән интегүчеләр булган кешеләр, шулай ук 50 яшьтән узган һәркем елга бер тапкыр булса да колоноскопия узарга тиеш. Япониядә кайчандыр эчәклек яман шеше әлеге зәхмәтнең иң еш очрый торган төре санала иде. Күптән түгел аларда диспансеризация программасына мәҗбүри рәвештә колоноскопия һәм ФГДС узу таләбе кертелде. Шуннан соң кыска вакыт эчендә Япониядә эчәклек яман шеше иң сирәк очрый торган төргә әверелде.

:: Эчке органнарга чыккан полиплардан куркырга кирәкме?

– Полип зарарсыз шеш санала. Ул еш кына ашказаны, эчәклекләрдә очрый. Аларны да даими рәвештә тикшертеп, контрольдә тотарга кирәк. Зарарсыз дип тынычланырга кирәкми. Игътибарсыз калдырсаң, вакытында алдырмасаң, тора-бара алар да яман шешкә әверелергә мөмкин.

:: Кайнар чәй эчү белән мавыксаң, кызлачакта ашказанында, йоткылыкта яман шеш хасил булырга мөмкин, диләр. Бу сүзләр ни дәрәҗәдә дөреслеккә туры килә?

– Бу сүзләрдә хаклык бар. Артык кайнар чәй, кайнар ризык йоткылыктагы лайлалы тышчаны пешерә. Көн дә шулай пешә торгач, ул урында яман шеш пәйда булырга мөмкин. Шуңа күрә чәйне дә, ризыкны да җылымса килеш ашарга, эчәргә кирәк.

vk.com

:: Коронавирус белән авырып терелгәннән соң яман шеш ачыкланган кешеләр дә бар. Бу очраклык кына микән? Әллә ковид яман шешкә сәбәпчеме?

– Коронавирус теләсә кайсы чирнең башлангычы була ала, булганнарын азындыра. Яман шеш тә искәрмә түгел. Әле күптән түгел генә шундый очракка тап булдым. Бер пациентымның үпкәсендә зарарсыз шеш бар иде. Аны гел тикшертеп торды. Коронавирус белән авырганнан соң ул кисәк кенә үсә башлады, яман шешкә әверелде. Шуңа күрә тәнендә зарарсыз дип саналган шешләре булган кешеләргә коронавирус белән авырган очракта сәламәтлегенә аеруча игътибарлы булырга кирәк.

:: Пластик операция ясаткан, бигрәк тә күкрәкләрен зурайткан-кечерәйткән гүзәл затлар арасында да яман шеш очраклары еш күзәтелә, диләр...

– Пластик операция ясар алдыннан күкрәк бизләре яхшылап тикшерелә. Операция ясагач, организм имплантны кабул итмәгән, төзәлми торган яралар хасил булган, күкрәктә яман шеш пәйда булган тискәре очраклар, дөрестән дә, күзәтелә. Әмма мондый яман нәтиҗәләр килеп чыгу ихтималы 10 проценттан да азрак.

Бу кызык!

ХОЛКЫҢ НИНДИ – ЧИРЕҢ ШУНДЫЙ

Баксаң, адәм баласының нинди чирдән интегүе турыдан-туры аның холкына бәйле икән. Британия галимнәре шулай дип ышандыра.

✷Гел төшенкелеккә бирелүчеләрнең ашказаны һәм башы еш авырта.

✷Агрессив кешеләр гипертониядән интегә, иммунитетлары нәзберек була.

✷Оялчан кешеләрдә инсульт булу ихтималы зур, алар йөрәк өянәкләренә һәм төрле инфекцияләргә тиз бирешә.

✷Хис-кичерешләрен тышка чыгармаучылар астмадан интегә.

✷Аралашучан, хисчән кешеләр күп авырулардан сакланган кешеләр төркеменә керә. Алар проблемалары белән бүлешергә курыкмый һәм бик тиз савыгалар.

✷Саран кешеләрнең – башлары, куркак кешеләрнең бөерләре авырта.

✷Оптимист кешеләр тормышны бик җиңел кабул итәләр, бөтен нәрсәдән рәхәтлек алырга телиләр. Ашау мәсьәләсендә дә үзләрен чикләмиләр. Шуңа күрә алар арасында сәламәт кешеләр күп.

✷«Юк» дип әйтә белмәүчеләр, нәрсә кушсалар, шуны үтәүчеләр артриттан интегә.

✷Башларында чамадан тыш мәгълүмат булган кешеләр эчләре катудан интегә.

Үзем сынадым

Ютәлдән коткаручы рецепт

Ютәлдән коткара торган файдалы төнәтмә ясый башладым. Рецептын сезнең белән дә бүлешим әле. Аны ясау өчен 500 грамм суганны чистартып, вак итеп турарга, шуңа 400 грамм шикәр кушып болгатырга кирәк. Аннары катнашманы 1 литр суга салып, 3 сәгать буе талгын утта кайнатам. Соңыннан плитәдән алып, бүлмә температурасына кадәр суытам да шушы кайнатмага 50 грамм бал салып эретәм. Әлеге кайнатманы ашар алдыннан балаларга – 4–6 бал кашыгы, өлкәннәргә 4–6 аш кашыгы эчәргә кирәк.

Әлмәттән ФИРАЯ апагыз

Белә идегезме?

ИНСУЛЬТТАН САКЛЫЙ

Америка галимнәре тикшерүенчә, шоколадтагы флавоноид дигән матдә организмда кан йөрешен тәртипкә сала, инсульт һәм параличтан саклый. Калифорния университетының туклану буенча белгече Карл Лин фикеренчә, бер кисәк әче шоколад 6 алма, 4–5 чынаяк чәйне алмаштыра.

КИШЕР КОТКАРА

Кишер ашагач, авыз куышлыгы микроорганизмнардан чистара. Ангина, стоматит, грипп булганда кишер согы белән авызны һәм тамакны чайкыйлар. Борынга томау төшкәндә 4 өлеш кишер согына 3 өлеш үсемлек мае, 1 өлеш сарымсак согы кушып, борынга тамызалар (көнендә 3–4 тапкыр, өчәр тамчы).

ӘХ, МУНЧАСЫ!

Кем генә мунча яратмый икән! Атна буе эшләп талчыкканнан соң мунча керү «яңадан тугандай» итә. Замана белән алар да үзгәреп тора. Мунча җанга һәм тәнгә сихәт бирсен өчен нинди булырга тиеш? Аны салуның нинди серләре бар?

Әлеге сорауларга, югары белеме булса да, балта эшен сайлаган, 17 елдан артык мунчалар салучы Назир МОСТАФИН белән җавап эзләдек.

Агынмы, карасынмы?

– Хәзерге вакытта кешеләр күбрәк ак мунча салып бирүемне сорый. Кара мунча турында белеп тә бетермиләр. Анысын сораучы сирәк хәзер. Ә кара мунчаның йөрәккә дәвасы зур. Анда бер микроб та калмый. Шунысын белеп бетермиләр, – ди Назир. – Мунчаның төрлесе бар. Томалап керә торганы, ягуга юынып була торганы да бар. Томалап кергәндә, без утын ягабыз да ис беткәнне берничә сәгать көтәбез. Аның бер сере бар: нарат агачы яксаң, исе тиз бетә. Имәннекен озаграк көтәргә кирәк. Соңгы елларда томалап яга торган мунчалар кимеде. Кайберәүләр ягуга ук кереп юына торган мунча сайлый. Газ белән ягыла торганы да бар. Күршеләре төтен чыга дип зарланмасын өчен анысын шәһәрдә яшәүчеләр сайлый. Хәзер ак мунчаның чит ил агачларыннан эшләнгәннәренә өстенлек бирүчеләр артты. Алар өчен мунчаның гади генә такталардан булуы түгел, төрле матур дизайннар белән эшләнүе дә мөһим. Мунчаның мича өйдән ераграк урнашкан булуы ошый. Юынып чыккач, саф һава сулап керүләре ни тора!

Түшәме юкә булсын

– Мунчаны акча кызганмыйча, яхшы агачтан төзергә кирәк. Агач мунча иң рәхәте, – ди Назир. – Бу эштә иң мөһиме – мунча бурасын сатып алганда ялгышмаска кирәк. Бүрәнә киңлеге 14 см булырга тиеш. Аны хәзер 7 см киңлектә генә итәләр. Бу очракта бүрәнә араларында һава йөри башлый һәм мунча тиз чери. Безнең якларда мунча бурасын күбрәк нарат, чыршыдан бурыйлар. Әмма ул сагызлы булса, җылынган саен өстегезгә агып утырырга мөмкин. Шуңа күрә түшәмен юкәдән ясарга киңәш итәм. Чабыну өчен бөтен төрле мунча яхшы. Әмма анда һава йөрергә тиеш.

Нигезе ныкмы?

– Фундаментны мунча салына торган җиргә карап эшлибез. Миңа «ленточный свайный» дигән ысул белән эшләү ошый. Субайлар бораулап, аңа арматура төшерелә. Аларны 40 см тирәнлегендәге чокыр казып, таш тутырып «заливать» итеп тоташтырабыз. Җир өслегенә чыгарылганнан соң, яңадан кирпеч өеп, 15 см күтәрәбез. Мунчаны кирпечтән салырга уйласагыз, нигезенең ныклыгына аеруча игътибар итәргә кирәк. Югыйсә, җир уйнап, мунча ярылырга мөмкин, – дип киңәш бирә Назир.

МУНЧА КЕРҮ БУЕНЧА КИҢӘШЛӘР

✓Парлы мунчада эшләр беткәч, кич белән юынырга кирәк.
✓Мунчада сыра эчмәгез! Аны компот, морс, үлән чәе, минераль суга алыштырыгыз.
✓Ләүкәгә утырганчы, өстегезгә салкынча су сибегез.
✓Керүгә чәчегезне юешләмәгез, эссе тияргә мөмкин.
✓Ләүкәдә утырганда башыгызга башлык киегез яки сөлге чорнагыз.
✓Парлану өчен тәнне кайнар һавага әкренләп күнектерегез.
✓Керүгә ташка су сипмәгез.
✓Ләүкәдә утырып түгел, ятып торыгыз. Борын белән сулагыз.
✓Ләүкәдән төшкәч, салкынча рәхәт су белән коеныгыз, тәнне бераз суытыгыз.
✓Ләүкәгә икенче тапкыр менгәндә генә себерке белән чабыныгыз.

Идәне коры булсын

– Хәзерге мунчаларга идәнне газ белән җылытыла торган итеп ясыйбыз. Ә мунчаны утын белән ягасыз. Идән юешләнеп тормаса, ул череми. Идәнне бетон җәеп ясау иң арзанлы да, чыдамлы да. Аны аз гына авыш итеп ясарга кирәк. Агачтан рәшәткәле идән ясыйсың да мунча кергәндә генә җәясең. Мунча коры торса, аның исе дә башка була. Идәне кибеп бетмәгән мунчага тынчу ис тарала. Чиста булсын, кибеп торсын, дисәгез, юынып беткәннән соң мичкә берәр утын ташлагыз. Коры итеп тотсаң, ләүкә, мунчаны эчләгән такталар 10 ел хезмәт итә, – ди ул.

Мичнең кайсы яхшы?

– Хәзер мунча миченең нинди генә юк. Һәркем үз мөмкинлегенә карап үзенә кирәклесен сайлап алырга мөмкин. Бервакыт мин берәүләргә 600 мең сумлык мич куйдым. Аңа су да саласы түгел, бер төймәгә басасың да парны үзе җибәрә, – ди Назир. – Мичне атнага ничә тапкыр мунча керүегезгә карап сайлагыз. Атнага бер генә керсәгез, артык кыйммәтлесе кирәкми дә. Әгәр көн саен ягып, өчәр сәгать юынасыз икән, бу очракта чыдамлырак мич сайларга киңәш итәм. Тагын шунысы да бар: мичне мунчаның җылытыла торган мәйданына карап сайлыйлар. Зур мунчага – зур, кечесенә кечкенә генә кирәк. Мичнең кемдер – тимерен, кемдер корычын сайлый. Корыч мич озак җылына, озак тора. Тимер дә начар түгел.



Ташы түгел, себеркесе мөһим

– Элек кырдан тишекле таш җыеп салалар иде. Кемнәрдер ком арасыннан чыккан йомры ташка өстенлек бирә. Иң мөһиме – мунчага салына торган таш җитешкән булсын. Аңа чүкеч белән сугып карарга кирәк. Әгәр чәчелеп таралмаса, яхшы дигән сүз. Мунча керү өчен иң яхшысы таш түгел, ә яхшы себерке кирәк.

Ләүкәң уңайлымы?

– Аны нинди агачтан эшләү мөһим. Ләүкә кечкенә булмаска, дөрес итеп ясалырга тиеш. Анда бер кеше яки ике кеше ятарлык урын булсын. Ләүкәне Г яки П хәрефе формасында ясарга киңәш итәм. Ул ике биеклектә булса, тагын да әйбәт. Аскы өлешендә утырып юынырга да була. Ләүкәне имән, каен агачыннан ясасагыз, ул яхшы кыза. Юкә белән усактан да эшләп куярга була. Әмма усак астма авырулыларга килешмәскә мөмкин. Хәзер абаш, кедр агачыннан эшләнгән ләүкәләргә өстенлек бирүчеләр бар. Әмма алар кыйммәтрәк. Тагын бер киңәш: ләүкә астына яктырткычлар куегыз. Мунчаның чиста һәм матур булуы да кирәк, – ди Назир.

Тәрәзәңне ач

– Нинди генә мунча булса да, анда һава йөрергә тиеш. Тәрәзәне ачып торуга карап ул суынмый, дымы гына китә. Хәл беткәндә дә тәрәзәне ачып алырга була, – ди оста.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Үзем сынадым

Файдалы фацелия



Бакчачы блогер Рәмзия Әхмәдуллина социаль челтәрләрдә сидерат буларак фацелия кулланырга киңәш итә.

– Гәрчич чәчкәч, бакчаны бет баса, ә сидератның файдасын күрәсе килә, диләр. Мин сезгә сидерат буларак фацелия тәкъдим итәм. Фацелия – чәчәк атучы берьеллык үсемлек. Чәчәге матур, исе тәмле, бик матур үлән. Аны бал кортлары да үз итә. Иртәрәк чәчкән очракта орлыгын да җыеп алырга мөмкин. Бер генә минусы бар – орлыгы кыйммәтрәк, ди ул.

Бәрәңге яшәртә

Муендагы «буразна»лардан түбәндәге битлек ярдәм итә. Аның өчен бәрәңге боламыгына 1 аш кашыгы глицерин, 1 чәй кашыгы зәйтүн мае салып болгатырга. Әлеге катнашманы тукымага җәеп муенга куярга һәм 15–20 минут өстеннән шарф белән урап тотарга. Берничә тапкыр кулланганнан соң, муендагы җыерчыкларның кимүе сизеләчәк.

Тәмле булсын!

АЛМАЛЫ КОЙМАКЛАР

Гөлфия ЗӘЙНУЛЛИНА рецепты

Кирәк: 1 данә алма, 150 мл кефир, 1 йомырка, 4 аш кашыгы он, 0,25 чәй кашыгы серкә белән сүндерелгән сода, 1 чеметем дарчин һәм тоз, 1 чәй кашыгы шикәр комы.
Әзерләү: савытка кефир, йомырка, тоз, шикәр комы, дарчинны салып болгатырга. Аңа эре угычтан уылган алма өстәргә. Он һәм соданы салып болгатырга. Аннары кыздырылган майлы табада пешерергә. Табынга куертылган сөт яки бал белән бирергә.

БЕР ЕЛМАЮ ДА ҖИТӘ

Октябрьнең беренче ун көнендә өлкәннәргә аерым игътибар күрсәтелә. Йөрәкләре картаю белмәгән өлкәннәребезгә мөселман өммәтендәгеләр нинди мөнәсәбәттә булырга тиеш? Яшь буын тәрбиясендә аларның өлеше нинди?

Бу һәм башка сорауларга җавапны Наил хәзрәт ЙОСЫПОВ белән эзләдек.

:: Диндә өлкәннәргә хөрмәт турында ни диелә? Сөекле пәйгамбәребез (с.г.в.) олыларга нинди мөнәсәбәттә булган?

– Өлкәннәрне хөрмәт итү турында Мөхәммәд (с.г.в.) бер хәдистә болай ди: «Кем дә кем кечкенәбезгә карата рәхимле булмаса, өлкән кешебезне олыламаса һәм галимебезнең хакын белмәсә, ул бездән түгел». Ягъни ул Аллаһ һәм Мөхәммәд (с.г.в.) күрсәткән юлдан бармый. Бу хәдис олыларга хөрмәт күрсәтүнең ислам динендә зур урын алып торуын аңлата. Гомумән, пәйгамбәребезнең (с.г.в.) олыларга карата хөрмәте бөтен тормыш юлында чагыла.

:: Мөселман кешесе өлкәннәргә нинди мөнәсәбәттә булырга тиеш?

– Иң беренче чиратта, олыларга хөрмәт күрсәтү очрашкан вакытта аларга беренче булып сәлам бирүдә күренә. Ислам әдәбе буенча яшь кеше үзеннән өлкәнрәккә беренче булып сәлам бирергә тиеш. Мөхәммәд (с.г.в.) әйтә: «Кечкенә олыга, узып баручы утырып торучыга, әз төркем күп төркемгә (беренче булып) сәлам бирә». Икенчедән, сөннәт буенча ризык кабул итүне иң беренче өлкән яки хөрмәтле кеше башларга тиеш. Хүзәйфә (р.г.) әйтә: «Әгәр дә без Мөхәммәд (с.г.в.) белән бергә булсак, ризыкка Аллаһның илчесе кулын сузганчыга хәтле кагылмый идек». Әгәр берәр нәрсә бирергә туры килсә, мәсәлән, сулы савытны, ризыкны, башта өлкән кешедән башларга кирәк. Мөхәммәд (с.г.в.) шулай ди: «Миңа Җәбраил фәрештә өстенлекне өлкәннәргә бирергә кушты». Хәтта мәчеттә җәмәгать белән намаз уку рәвеше дә олыларга хөрмәт күрсәтергә өйрәтә. Мөхәммәд (с.г.в.) әйтә: «Кешеләргә имам булып Аллаһның китабын оста укучы (яхшырак белүче) баса. Әгәр аларның укуы бер дәрәҗәдә булса, сөннәтне яхшы белүче, әгәр дә сөннәтне белүдә бертигез булсалар, алданрак һиҗрәт кылучы, әгәр дә инде һиҗрәт кылуда да бертигез булсалар, яше буенча олырагы имам булып баса». Шулай ук намазга тезелгәндә дә иң беренче булып олылар, ә аларның артларына яшьләр һәм балалар баса. Сүз башлаган вакытта сөннәт һәм әдәп буенча беренче итеп бу мөмкинлек олыларга бирелә.

:: Хәзер яшь гаиләләр балаларны әбибабай тәрбиясеннән мәхрүм итә. Янәсе, заманча үстерәләр. Үсеп килүче буынны тәрбияләүдә өлкәннәрнең роле нинди?

– Яшь буынны тәрбияләүдә өлкәннәрнең роле гаять зур. Бу аларның зур тормыш тәҗрибәсенә ия булулары, дөньяда күпне кичерүләренә бәйле. Менә шуңа күрә дә алар яшьләргә үзләренең акыллы киңәшләрен бирә ала. Аларда тәҗрибә, акыл һәм хикмәт яшьләргә караганда күбрәк. Шуңа Аллаһы Тәгалә һәм Мөхәммәд (с.г.в.) аларны хөрмәт итәргә куша. Әгәр дә яшь кеше үзеннән өлкәнрәккә хөрмәт күрсәтсә, олыгайгач аның үзенә дә шундый ук хөрмәт күрсәтәчәкләр. Мөхәммәд (с.г.в.) әйтә: «Әгәр дә яшь егет өлкән яшьтәге картны хөрмәтләсә, Аллаһ картлык көнендә аны хөрмәтләүче кешене билгеләячәк».

Шулай ук балалар да әти-әниләренә карата нинди мөнәсәбәттә булсалар, аларның балалары да аларга карата шундый ук мөнәсәбәттә булачак. Мөхәммәд (с.г.в.) әйтә: «Әти-әниләрегезгә изгелек кылыгыз, балаларыгыз да сезгә игелек кылучы булырлар». Әгәр дә кеше яшь вакытта үзенең әти-әнисен санламаса, рәнҗетсә, хакын үтәмәсә, килер бер көн, балалары да аңа шундый ук мөнәсәбәттә булыр. Аллаһы Тәгалә әйтә: «Кем дә кем яхшылык эшләсә, моның файдасы аның үзенә була, ә кем дә кем начарлык эшләсә, моның зарары үзенә булачак. Синең Раббың колларына әз генә дә гаделсезлек кылмый».

:: Өлкәннәр белән сөйләшкәндә нинди әдәп-әхлак кагыйдәләрен истә тотарга?

– Өлкәннәр белән сөйләшкәндә беренче булып исәнләшергә, аңлаешлы, ачык итеп, аның сүзен бүлмичә сөйләшергә, хөрмәт белән «сез» дип мөрәҗәгать итәргә кирәк. Кайда гына булмасын, беренче сүзне өлкән кешегә бирү күркәм гадәт, минемчә. Өлкәннәр белән бәхәскә кермичә, җай, тәртип белән сөйләшү зарур. Шулай ук пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) әйткәнчә: «Сөйләсәң, яхшы сүз сөйлә, булмаса, тик тор».

:: Олыгайган көннәрендә, балалары булып та, ялгыз калган әби-бабайлар бар... Ата-анасын махсус, белә торып картлар йортына илтеп тапшыручылар да җитәрлек...

– Картлар йортындагы әби-бабайларыбызны күреп йөрәк сыкрый. Иң гаҗәбе – күбесенең балалары исән-сау. Нинди намус, нинди вөҗдан, нинди иман белән моны башкарырга мөмкин соң?! Аллаһы Тәгаләгә барчабызның да кире кайтасы бар. Аның алдында җавап тотасы! Аллаһы Тәгалә бездән, һичшиксез, әти-әниебезнең күз яшьләре, аларга карата мөнәсәбәтебез турында сораячак. Изге Китапның ничәмә-ничә урынында ата-ана хакы турында әйтелә. Шуларның бер аятен мисал итеп китерәм. Аллаһы Раббыбыз әйтте: «Синең Раббың хөкем итте, Аңа гына гыйбадәт кылыгыз һәм әти-әниләрегезгә иң яхшы мөгамәләдә булыгыз». Ягъни ислам диненең иң зур хакы, иң зур тәгълиматы – Аллаһны бер һәм бар дип санау. Без, мөселманнар, Аллаһы Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә инанабыз һәм аңа гыйбадәт кылабыз. Икенче хак итеп Аллаһы Раббыбыз әти-әниләр хакын зурлый. Аларның хакы Аллаһ хакыннан соң килә. Шуңа күрә пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.): «Әти-әниенең ризалыгы – Аллаһ ризалыгы, әти-әниенең ачуы – Аллаһ ачуы», – диде.

:: Өлкәннәребезгә олыгайган көндә күңел көрлеген югалтмас өчен нинди киңәшләр бирер идегез?

– Аллаһ биргән гомергә сөенеп, шөкер итеп һәм узган тормышыгыздан алган тәҗрибәләрегезне бала-оныкларга җиткереп, аларга карата фатыйхада булып, аларга һәрдаим дога кылып, өлкәннәрнең бит догалары кабул була, озын һәм бәрәкәтле гомер кичерегез.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Октябрь аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	Шим	03:41	05:45	15:19	17:19	19:01
2	Якш	03:43	05:47	15:16	17:17	18:58
3	Дүш	03:45	05:49	15:14	17:14	18:55
4	Сиш	03:47	05:51	15:12	17:11	18:53
5	Чәрш	03:49	05:53	15:10	17:09	18:50
6	Пәнҗ	03:51	05:55	15:07	17:06	18:47
7	Җом	03:54	05:57	15:05	17:04	18:45
8	Шим	03:56	05:59	15:03	17:01	18:42
9	Якш	03:58	06:01	15:00	16:58	18:39
10	Дүш	04:00	06:03	14:58	16:56	18:37
11	Сиш	04:02	06:05	14:56	16:53	18:34
12	Чәрш	04:04	06:07	14:54	16:51	18:32
13	Пәнҗ	04:06	06:09	14:51	16:48	18:29
14	Җом	04:08	06:11	14:49	16:46	18:27
15	Шим	04:10	06:13	14:47	16:43	18:25
16	Якш	04:12	06:15	14:45	16:41	18:22
17	Дүш	04:14	06:17	14:42	16:38	18:20
18	Сиш	04:16	06:19	14:40	16:36	18:18
19	Чәрш	04:18	06:21	14:38	16:34	18:15
20	Пәнҗ	04:20	06:23	14:36	16:31	18:13
21	Җом	04:22	06:26	14:34	16:29	18:11
22	Шим	04:24	06:28	14:32	16:26	18:09
23	Якш	04:26	06:30	14:29	16:24	18:06
24	Дүш	04:28	06:32	14:27	16:22	18:04
25	Сиш	04:30	06:34	14:25	16:19	18:02
26	Чәрш	04:32	06:36	14:23	16:17	18:00
27	Пәнҗ	04:33	06:38	14:21	16:15	17:58
28	Җом	04:35	06:40	14:19	16:13	17:56
29	Шим	04:37	06:42	14:17	16:10	17:54
30	Якш	04:39	06:44	14:15	16:08	17:52
31	Дүш	04:41	06:46	14:13	16:06	17:50

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

Йөгез, бер дога!

Ир туганнар өчен

«Аллаһүммә-хфазһү вәхрусһү би ʼәйникә әлләти лә тәнәму вә кәллилһү би-с-сыйхати вәл-ʼәфия. Рабби лә турини фиһи әмран юъзини».

Мәгънәсе: «Йа Аллаһ, аны Үзеңнең бетмәс-төкәнмәс кайгыртуың белән сакла һәм аңа сәламәтлек һәм иминлек бир! Йа Раббым, миңа аның белән бәйле кайгыга сала торган нәрсәләрне күрергә насыйп итмә!»

***

«Аллаһүммә әәнисһү фи гурбатиһи вә әзхиб ʼаңһү әл-вәхшәтә вә әл-вәхдәтә би руфкати әс-салихин. Аллаһүммә күн ләһү фи сәфәриһи вә гурбатиһи хәйран минһә».

Мәгънәсе: «Йа Аллаһ, ерак җирләрдә аның юлдашы бул, һәм иманлы юлдашлар ярдәме белән аны борчудан һәм читләшүдән арала! Йа Раббым, өйдән еракта аның сәфәрендә безгә караганда яхшырак (ярдәмче) бул!»

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Ә син таныйсыңмы?

Уенның чираттагысын тәкъдим итәбез. Шартлар шул ук: җырчы һәм җырның исемен язып җибәрергә кирәк. Тулы, дөрес һәм беренче җавап бирүчегә бездән бүләк – телефонына 100 сум! Җавапларны +7 (904) 718-14-69 номерына юллагыз.

Газетабызның узган санында чыккан җырчы һәм җырларны танучы булмады. Рәсемнәр астына без Ришат Төхвәтуллин репертуарыннан «Төтеннәр», Зөфәр Билалов башкаруындагы «Җир астыннан юллар юк» һәм Хәния Фәрхинең «Ә мин менә сине сагынмыйм» җырларын яшергән идек.

Эшләрне Чүпрәле районы электр челтәрләре белгечләре ярдәме белән «Опора Плюс» подрядчы оешмасы хезмәткәрләре башкарып чыккан. Шунысын искәртик, эшләрнең барысы да көчәнеш астында башкарыла. Ягъни энергетиклар технологик тоташтыруны халыкны уттан өзмичә генә эшләгән.

Әлеге матур үзгәрешләрдән халык та канәгать, ди авыл советы башлыгы Илһамия Мухитова.

– Нинди генә сорау килеп чыкса да, энергетикларыбызга мөрәҗәгать итәбез. Бу эшләрне дә авыл халкы бик көтте, чөнки көчле җил, буран булса, яңгыр яуса да, утны сүндереп торырга туры килде. Вакыт-вакыт ут сүнеп киткән очраклар да булды. Шуңа күрә башкарылган эш күләме зур иде. Меңгә якын электр баганасы гына кайтарылды, урамга утлар өстәлде. Халык энергетикларга бик рәхмәтле, – диде ул.

...ДҮРТЕНЧЕ SMS: «ТҮЗӘ АЛМАДЫМ, ЭШТӘН КИТТЕМ»

Тиздән халыкара Укытучы көне. Республикадагы укытучыларга бәйле вазгыять, кадрлар әзерләү мәсьәләсе, аларга булган хөрмәт турында педагогика фәннәре докторы, КФУның психология һәм мәгариф институты директорының укыту эшләре буенча урынбасары, белем һәм тәрбия бирү методологиясе кафедрасы мөдире Алмаз ГАЛИМОВ белән сөйләштек.

:: Алмаз Мирзанурович, республика вузлары укытучылар әзерләсә дә, яшьләрнең күбесе мәктәпкә барып җитми, барган очракта да төпләнеп калмый. Бу проблеманы ничек хәл итеп була?

– Дөресен генә әйткәндә, алар мәктәпкә барып җитә. Проблема барып җитүдә түгел, ә анда төпләнеп калуда. Беренчедән, бездә 3–4 нче курста укыганда ук студентларның 80–90 проценты үз һөнәре буенча эшли башлый. Тик хезмәт хакы түбән булу, мәктәптәге бюрократия, әти-әниләр белән мөнәсәбәтләр башка эшкә күчәргә мәҗбүр итә. Бөтен гаепне хәзер укытучыдан эзлиләр бит. Бу да аларның гайрәтен чигерә. Шулай ук яшьләр: «Бөтен көчемне түгәм, әмма юньле хезмәт хакы түләнмәгәч, нигә мәктәптә эшләп йөрергә?» – диләр. Укытучы эше – үзенчәлекле, аны яратырга кирәк. Яратмаганнар бу белгечлеккә укымый да, мәктәптә дә эшләми.

Бер мисал китерәм. Без студентлар вузны тәмамлагач та, аларның ничек эшләве турында кызыксынып торабыз. Бер кызыбыз башлангыч сыйныф укытучысы белгечлеге алып, мәктәпкә урнашты. Ул кыз башта кураторына, барысы да ошый, дип рәхмәт әйткән. Бер-ике айдан исә, безнең мәктәптә берничә башлангыч сыйныф укытучысы җитми, миңа тагын бер сыйныфны бирәләр, барасым килми, дип язган. Өченчесендә эшнең икеләтә авыр булуын әйткән. Дүртенче SMS – «түзә алмадым, мин эштән киттем». Күрәсезме, яшьләрне килү белән мәктәптә шундый шартларда калдыралар. Әлбәттә, алар түзә алмыйлар. Аларның мәктәптә төпләнеп калмавында, педагоглар җитмәүдә югары уку йортларының гаебен күрмим. Монда педагогик мохит, система эшләп бетерми.

:: Биш ел укытучылыкка укып, пицца сатып йөрү эш түгел бит инде...

– Укытучылар проблемасы мөһим, шуңа күрә аны бар кеше күтәреп чыга. Хәзер карыйк икътисадчыларны. Аларның ничә проценты үз эшендә, күпмесе полициядә, сак хезмәтендә, башка өлкәләрдә хезмәт куя яки шул ук пицца сата? Юрист, инженерларны алыйк. Шул ук инженер белгечлегенә укып бетерәләр дә, дистәләгәне башка юнәлештә эшли башлый. Ул өлкәләрдә проблема тагын да күбрәк. Үз һөнәре буенча эшләмәгән педагоглар саны башка белгечлекләргә караганда күпкә кимрәк. Нишләп мәктәптә калмыйлар? Әйткәнемчә, барасы килмәгәнгә яки вуз укытучы эшенә тиешенчә әзерләмәүдән түгел, алар шартлардан канәгать түгел. Үзем дә яшь укытучы булган кеше. Укытучыларның күбесе шәһәрдә туып үсмәгән. Шулай булгач, фатирга түләргә, гаиләне туендырырга кирәк. Яшь бала белән булгач, хатының эшләми дигән сүз. 18–20 мең сум хезмәт хакы алып, ни күзең белән өеңә кайтырга кирәк? Казан мәктәбенә эшкә урнаштым, балабыз туды. Шәһәрнең иң читендәге иң арзанлы фатирны арендаладык. Кыз белән кичен саф һава суларга чыгабыз, чупа-чупс сорамасын дип, киоскларны урап үтә торган идек. Болай булырга тиеш түгел. Ярый, мин түзеп, шушы системада калдым. Яшьләрнең күбесенең сабырлыгы җитми. Мин таксида йөртеп, 3–4 мәртәбә күбрәк акча алачакмын, ди ул. Шул ук вакытта вазгыятьнең кире кайта башлавы да күзәтелә. Бергә укыган дүрт алты ел физика укытканнан соң риэлтор, кадастр инженерлары булып эшли башлады. Бер ел элек мәктәпкә кире кайтты. Аның әйтүенчә, директор өстәлендә тагын берничә физика укытучысының гаризасы ята икән. Илдәге хәлләр үз йогынтысын ясамыйча калмады: акча җиңел табучы өлкәләрдә вазгыять үзгәрде. Башка өлкәдә эш урыннары кими башлагач, мәктәпкә кайта башладылар.

:: Бер мәктәптә директор булып эшләүче физика укытучысы алай дими шул. Атнага 20шәр сәгать физика укытам, дип зарлана. Укытырга укытучы таба алмыйча интегәм, ди.

– Кытлык бар. Ул физикага гына түгел, барлык фәннәргә дә кагыла. Иң күбе башлангыч сыйныф укытучылары җитми, диләр. Мәсәлән, быелгы уку елында республика буенча 541 укытучы кирәк булган. Республика Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматларына караганда, уку елы башына 2659 укытучыга ихтыяҗ бар иде. Әйтик, математикадан – 367, рус теленнән – 288, физикадан – 166, химиядән – 106, физкультурадан – 71, татар теленнән 90 укытучы кирәк дигән сүз бу. Без кирәгенчә әзерлибез. Алар мәктәпкә йә барып җитми, йә калмыйлар. КФУда бүген укытучылыкка 10969 студент белем ала. Ел саен 2 мең укытучы чыгарыла дигән сүз бу. КФУ – Россиядә укытучылар әзерләүче иң зур вузларның берсе. Моннан тыш әле Чаллы, Алабугадагы педагогик уку йортлары бар. Җиде елга исәпләнгән фаразлар буенча, 2023–2024 уку елына – 1388, 2024–2025 елда – 1154, 2028–2029 елга 863 укытучы кирәк. Чынлыкта фаразлар чынбарлыкка туры килеп бетми, ихтыяҗ зуррак.

:: Авыллардагы укытучылар кытлыгын киметү өчен «Авыл укытучысы», «Мобиль укытучы» проектлары тормышка ашырыла башлады. Ничек уйлыйсыз, акча яки бер авылдан икенчесенә йөреп укыту өчен машина биреп кызыктыру дөресме?

– Мондый проектлар – замана таләбе. Дөресрәге, укытучылар кытлыгын бетерү өчен шулай эшләргә мәҗбүр булдылар. Башта авылларда мәктәпләрне кыскарттылар. 250шәр хуҗалыклы авылларга да кагылды бу. Килешәм, балалар саны аз. Тик 40–50 укучысы булганнары да бар иде бит. Аларны хәзер күрше авыл мәктәпләренә автобус белән йөртәләр. Мәктәп булмагач, укытучылар башка эшкә күчте, авылдан китә башлады. Хәзер менә укытучылар җитми. Дөнья үзгәрә, балалар туа тора. Ил белән башка халәткә күчәбез. Халык кире авылга кайта башласа, бу мәктәпләрне кире ачарга да туры килмәгәе. 2–3 бала булса да, башлангыч мәктәпне сакларга кирәк. Мәктәп ул – авылның йөрәге. Бөтен чаралар шунда уза, халык шунда кайный бит. Мәктәп бетсә, авылның йөрәге туктый. Өй төзеп бирәләрме, хезмәт хакын күтәрәләрме, процентсыз кредит бирәләрме – барысын да хупларга кирәк, чөнки укытучыларның аңа хакы бар.

:: Бүген күпләребез укытучы образын болайрак күрә. Ул төне буе дәфтәр тикшерә, план яза, мәктәптә туктаусыз хисап тутыра... Элек, укытучы бәрәңге ашыймы икән, дип кызыксына идек. Укытучы образы бүген үзгәрдеме? Сез ничек күзаллыйсыз?

– Баладагы, халыктагы, җәмгыятьтәге укытучы образы – барысы да үзгәрде. Без укыгандагы укытучы образы ул – идеал, белем нигезе, киләчәккә ишек. Хәзер башкача. Менеке башка кешенеке белән туры да килмәскә мөмкин. Укытучы үз эшенә бирелгән. Дәфтәр тикшерү ул – укыту эше, баланың белемен бәяләү. Ул дөрес этап, шулай булырга тиеш. Хәзерге педагогның йончуы аның дәфтәр тикшерүенә бәйле түгел. Төрле өстәмә эшләр йөкләүдән бу. Ул сайлауда да, семинар, курсларда да, башка чараларда да катнашырга тиеш. Аны бертуктаусыз тегендә-монда тарткалыйлар. Синең укучыларыңа олимпиадаларда катнашмыйча да калырга ярамый. Укытучының белемен шул хисапның күләменә карап бәялиләр. Кәгазең бар икән – афәрин, берничә булса, тагын да яхшырак. Биш икән – син әйдәп баручы укытучы! Моны шартлы рәвештә әйтәм. Син дәресеңне ничек алып барасың, укучыларың синең фәнеңә нинди мөнәсәбәттә, алар тормышта үз юлларын ничек таба – монысы берәүне дә кызыксындырмый.

:: Хәерлегә булсын, соңгы вакытта тәрбия турында да сүз кузгата башладылар...

– Тәрбия мәсьәләсен үзгәртү буенча эш алып баралар. БДИга гына әзерләү, синең балаңның күпмесе дәрәҗәле вузга керү күрсәткече мәктәп системасында төп нәрсә түгеллеген, ниһаять, аңлый башладылар. Гимн башкару, флаг күтәрү, «Мөһим сөйләшү» дәресләрен кертү юкка гына түгел. Бу уйлап чыгарган нәрсә түгел, элек тә бар иде. Хәзер каршылыклы мөнәсәбәттә булсалар да, киләчәктә аны барысы да хупларлар дип уйлыйм.

БДИ мәсьәләсе дә борчый мине. Ике тискәре ягын күрәм. Берсе – югары баллар җыйган укучыларның чит вузларга китеп, кире әйләнеп кайтмавы. Бездә калырга тиешле талантлы балаларны Мәскәү үзенә суырды. Икенчесе – БДИның тәрбия системасын алыштыруы. Мәктәптә фәннәрне бары имтиханга әзерләнү юлы кебек кенә карыйлар, аның тәрбияви әһәмиятен онытттылар. Ул фәннең укучының дөньяга карашын, күзаллавын киңәйтүен бөтенләй төшереп калдырдылар. Шуннан чыгып та мәктәпкә һәм укытучыга мөнәсәбәт тискәреләнде. Аның бит әле татарга да зыяны бар. Үземнең туган авылыма кунакка кайткач, урамга чыксам, 7–8 яшьлек балалар русча сөйләшеп үтә. Йөрәк әрни моңа. Әти-әниләрдә дә гаеп бар. Чепчи татар авылларында, балам имтихан бирә алмый дип, русча укытуны сайлый. Татарча укыса, БДИ бирә алмый, кеше була алмый, янәсе. Татар мәктәбен бетерүчеләрнең берсе дә югалып калмады. Арада менә дигән галимнәр, инженерлар, югары урыннарда эшләүче белгечләр бар.

:: Укытучы көне якынлаша. Сез кемнәрне беренче булып котлыйсыз?

– Беренчедән, әтием Мирзанурны. Аңа 91 яшь. Заманасында 40 елга якын Мөслим районының Метрәй мәктәбен җитәкләде, балаларга математикадан белем бирде. Безнең авылдан гына да 40лап математика укытучысы чыгарды. Нәселебезнең укытучылык буенча хезмәт стажы – 145 ел. Беренче укытучым Нурсөя Шәмсиева, сыйныф җитәкчесе Мөхәйминә Галиева, башка укытучыларны да онытмыйм. Гадәттә, укытучылар бәйрәменә авылга кайтырга тырышам. Барлык укытучыларны да якынлашып килүче һөнәри бәйрәмнәре белән котлыйм. Аларга сабырлык, сәламәтлек, үз эшләренең остасы булуын, иҗат дәрте сүнмәвен телим.

Сәрия МИФТАХОВА

ӘҢГӘМӘНЕҢ ТУЛЫ ВАРИАНТЫ – VATANTAT.RU САЙТЫНДА

СЫНАУЛАРНЫ ҮТӘ БЕЛҮ КИРӘК

Әлки районының Татар Борнае кызы Гөлназ Сәгыйрованың кулыннан килмәгән эше юк. Булдыра алмам, килеп чыкмас, дигән сүзләрне белми ул. Эшләсәм – җиңәрлек, тотынсам, башкарып чыгарлык булсын, дип яши. Җиңү дигәнне тикмәгә генә әйтми. Гөлназ физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләр арасында узучы «Абилимпикс» бәйгесендә катнашып, 2018–2020 елларда зур уңышларга ирешкән иде.

Гөлназга тумыштан ДЦП диагнозы куелса да, көчле рухы аны җиңәргә ярдәм итә. Дөресрәге, чире чигенми, әмма Гөлназ бу хакта аз уйларга тырыша.

– Мин – гаиләдә икенче бала. Әтиәнием мине бик кадерләп үстерде. Аеруча әти белән икебезне бәйли торган күренмәс җепләр бар. Шул рәхәт хисләр, әти яратуы яшәтә инде мине. Башка әти булса, мин мондый булмас идем. Кыз балага әти җылысы бик кирәк, – ди Гөлназ. – Гап-гади авыл мәктәбендә укыдым. Аякларым авырткач, укуым күбрәк өйдә узды. Мәктәпне тәмамлагач, Димитровград шәһәрендә һөнәри белем алдым, аннары Казан технология һәм дизайн көллиятен тәмамладым.

Көллияткә килгәч, Гөлназ тегү белән кызыксына башлый. Киемнәр тегә. Бәйгедә катнашып карарга тәкъдим булгач, ике дә уйлап тормыйча ризалаша. 2018 елда тегүче һөнәре буенча «Абилимпикс»та катнашып, Татарстан буенча беренче урынны яулый. Укытучылары аңа «Визаж» буенча да үз осталыгын күрсәтергә киңәш итә. Кыз монысында да югалып калмый. Татарстанда – алтын, Россия буенча бронза медаль яулый. Тагын бәйгегә чакыралар. Бу юлы «Флористика» буенча үз осталыгын күрсәтергә алына. Тренерларына максатын алдан ук әйтеп куя: җиңәрлек итеп өйрәтегез! Көненә 17 сәгать шөгыльләнү бушка китми, Гөлназ монда да җиңә! Аны Россия җыелма командасына алалар. Флористика эше үзенә дә ошап китә. Яңадан укый, чәчәкләр турында күп өйрәнә. Хәзер чәчәк кибетендә эшли.

Ә кибеткә аны... чарасызлык китерә. Ул мошенниклар корбаны була. Үзен телефоннан алдауларын аңлаганда, Гөлназ исеменә 300 мең сум кредит рәсмиләштерелгән була инде.

– Ул чакларны искә төшерәсем дә килми. Үләсе килгән мизгелләр дә булды. Тик сабырлык җиңде, – ди Гөлназ. – Авыр хәлдә калгач, бер дустыма киңәшкә бардым. Ә ул, бу сиңа зур сабак булсын, диде. Шул сүз «терелтте» мине. Үземне кулга алдым. Мәскәүгә ярышларга барасы идем, тиз генә җыенып, анда чыгып киттем. Кайткач, дус кызыма эш сорап яздым. Шулай салонга килдем. Бу вакыйга минем күзләремне ачты. Моңарчы кешеләр белән аралашырга яратмаган Гөлназ көненә 12 сәгать эшләргә өйрәнде. Ул кредитны 470 мең сум итеп түләдем инде.

Гөлназ дин юлына да баскан. Кечкенәдән, аяклары башкаларныкы кебек булмагач, ул әбисенә гел сорау бирә торган булган. Нинди гөнаһларым өчен, дип күп борчылганнар. Ә аннан... эпилепсия чире башланган. Терелгәч, яшәү рәвешен үзгәртә. Догалар өйрәнә, ялгызлык яба.

– Минем әчке дөньям белән тышкысы тәнгәл килә. Үз-үзем белән гармониядә яшим. Шулкадәр рәхәт. Күз атучылар, бүләкләр бирүче егетләр дә бар. Үземне башкалардан бер дә ким күрмим. Шөкер

итеп яшәрлек кенә, – ди ул. – Мине хыял яшәтә. Алар бик күп. Үзең тырышып чынга ашыра торганнары да бар. Әйтик, киләчәктә чәчәкләр остаханәсе булдырасым килә. Анда башкаларны да флористика серләренә өйрәтер идем. Монысын булыр дип уйлыйм. Күңелдә йөрткән тагын бер хыял – хаҗга барасым килә. Быел туган көнем Корбан гаетенә туры килде. Шуны бәйрәм иткәндә туды бу теләк. Изге җирләрне күреп кайт идең!

Гөлназның бер генә сәгате дә буш түгел. Көллияттә эшли, аннан чыккач, чәчәкләр салонына бара. Төрле бәйгеләрдә бәя бирүче эксперт та булып йөри әле. Татар эстрада җырчылары концертларына барырга да вакыт таба. Кыскасы, күңелсезләнеп утырырга вакыты юк. Шуңа ул үзе кебекләргә көчле булырга, үзенә килгән сынауларны җиңәргә өйрәнергә киңәш бирә:

– Мин элек гел үземнең халәтемнән читенсенә идем. Башкалар кебек биек үкчәле туфлиләр киясем дә килде. Әмма соңрак аңладым: Аллаһы Тәгалә мине сыный икән. Ә мин аны үтә белергә тиеш. Тормышыма зарланып булмый. Акрын гына булса да, үз аякларымда йөри алам. Күзләрем күрә, колакларым ишетә. Иң мөһиме – янәшәмдә мине якын итүче кешеләр күп. Алар көчле булырга ярдәм итә дә инде.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ХАЛЫК АВАЗЫ

7 октябрьдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист – **Сәрия Мифтахова** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

Акча артырмы?

Мин – пенсионер. Әлегә эшләп йөрим. Эштән китеп, бер ай эшләмәсәм, пенсия артырмы икән?

Арчадан укучыгыз

Россия Пенсия фондының Татарстандагы идарәсенең матбугат җитәкчесе Альбина Никандрова:
– Пенсионерның пенсиясе эштән киткәннән соң икенче айдан индексацияләнә. Пенсионерның эшләгән чорындагы барлык индексацияләрдән чыгып, пенсия күләме арта. Эштән китеп, 3 ай узганнан соң гына сезгә пенсиягез артып һәм бер юлы 3 ай өчен өстәмә түләнәчәк. Яңа пенсия күләме пенсионер янә эшкә урнашкан очракта да сакланып калачак.

Кайсын сайларга?

Социаль пакет кемнәргә тиеш һәм аны ничек алырга? Балалар, акчасын ал, диләр. Шул ук вакытта даруларның кинәт кыйммәтләнеп китүеннән дә куркам. Безнең яшьтә инде дарусыз да булмый...

ГӨЛФИЯ апагыз

Редакциядән. Хөрмәтле укучыларыбыз! Социаль пакетка бәйле язма безнең газета битләрендә урын алган иде инде. Шулай да аны алу кагыйдәләрен искәртү зыян итмәс.

2022 елда дару өчен бирелә торган акчаның суммасы – аена 1 мең сум. Социаль пакет сайлаган кеше дару гына алып калмый, моңа шифаханәгә юллама, дәвалану урынына бушлай бару һәм кайту, тимер юл транспортында бушлай йөрү мөмкинлеге дә керә. Төрле чирләренә дәва бирә торган кирәкле бөтен дарулар да бирелә. Моннан Бөек Ватан сугышы инвалидлары, анда катнашучылар, ауда үлгәннәрнең тол хатыннары, балалары, Ленинград блокадасында булучылар, төрле бәрелешләрдә булган ветераннар, радиациядән зыян күрүчеләр һәм барлык төр инвалидлар файдалана ала.

Социаль пакетны алыр өчен гаризаны пенсия бүлекләренә тапшырырга кирәк. Дару киләсе елның 1 гыйнварыннан бирелә башлый.

Бүләкне кайдан аласы?

Өлкәннәр көненә бүләк алу өчен нишләргә? Аны кемгә бирәләр?

РЕЗЕДА ханым

Редакциядән. Кызганыч, әлеге ханымның кайсы шәһәр-районнан икәнен ачыклый алмадык. Өлкәннәр көне уңаеннан бүләк алу өчен авыл җирлегенә, районның социаль хезмәт күрсәтү үзәгенә мөрәҗәгать итәргә киңәш итәбез.

P.S. Узган атнада укучылардан әнә шундый эчтәлектәге шалтыратулар кабул иттек. Сорау-хатларыгызга җавап тапмасагыз – борчылмагыз, димәк, аңа җавап эзләнә, тиешле урыннардан хат көтелә.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

Мөхтәрәм галимебез әйткән...

Күренекле милләттәшебез, дин галиме Ризаэтдин Фәхретдиннең «Әхлак гыйльме» әсәрендәге: «Ата вә анагызны, якын кардәшләрегезне ничек сөйсәгез – милләтегезне шулай сөегез, милләтегез өчен хезмәт итүне җаныгызга зур табыш дип санагыз», – дигән сүзләре игътибарга бик лаек. Димәк, галимебезнең милләтебез өчен борчылганы ачык сизелә. Тел булмаса, дәүләт тә була алмый. Бу – бәхәссез аксиома. Хәзерге вакытта татар телебез үги хәлдә. Җитәкчелегебез татар телен гамәлгә ашыру өчен тагын да җитдирәк чаралар күрер дип ышанып калам.

Сәгъдулла ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ

Укучы сүзе

ИҖАУДАГЫ ФАҖИГАГӘ БӘЙЛЕ ФИКЕРЛӘР

Кайчан мәктәпләрне Росгвардия саклый башлаячак? Пенсия яшендәге, физик әзерлеге булмаган апа-абзыйлар сакчы була алмый инде. Алар бит склад сакламый. Балаларыбызны кораллы, экипировкалы Росгвардия, полиция вәкилләре сакларга тиеш.

Зилә ШӘЙДУЛЛИНА

***

Үзебезнең йомшаклыкны, көн үткәнгә эшләгәнне, уйлап бетермәвебезне – барысын да югарыдагыларга сылтау – үзебезне аклау, минемчә. Матбугатта, җыелышларда, очрашуларда төртеп күрсәтер урынга мөрәҗәгатьләр белән чыгарга кирәк.

ФЛЕРА

Ижау һәм башка мәктәпләрдәге бу коточкыч, җан өзгеч вакыйганы мәктәпләрдә тәрбия булмау нәтиҗәсе дип карарга кирәк. Әгәр дә тәрбия темасы белән ямау салу, күрсәтү өчен генә шөгыльләнәбез икән, илне саклаучылар да, тынычлыкны яклаучылар да кими барачак.

Клара ФИЛИППОВА

ӨЛЕШЧӘ МОБИЛИЗАЦИЯГӘ БӘЙЛЕ ФИКЕРЛӘР

Гаиләләренә булышып торганны белеп китсеннәр, гаилә өчен дә эчләре пошып торырлык булмасын иде. Шулай зурлап озатып, зурлап каршы алырга насыйп булсын безнең геройларыбызны! Исәнимин йөреп, исән-сау кайтыгыз!

Фатыйма ВӘЛИУЛЛОВА

***

Безнең халыкны сындырмаслар, Аллаһ юл куймас. Безнең егетләребез дә илебезне хур итмәс. Алар бик көчле. Исән-имин, шатлык белән әйләнеп кайтсыннар. Кем булса да – татармы, чуашмы, урысмы – без бердәм халык. Алар – безнең балалар. Дөрт яктан рәхмәт фәрештәләре саклап йөртсен.

Гүзәлия ХӘЛИЛОВА

ЛӘЙСӘН ФӘЙЗУЛЛИНА:

«КҮҢЕЛЕҢ ЯТМЫЙ ИКӘН, ИНТЕГЕП ЭШЛӘРГӘ КИРӘКМИ»

Өч яшеннән сәхнәгә чыккач, аңа артист тормышы юрыйлар. Әнисе генә, бу һөнәрнең бөтен авырлыкларын үз башыннан кичергәнгә, сагаеп кала. Аның да башта сәхнәгә исе китми. Бер вакытка кадәр. Хәзер Ләйсән ФӘЙЗУЛЛИНА – Камал театрының әйдәп баручы артистларының берсе. Ул төрле. Мин аны дуамал, максатчан, кызыксынучан дип күзаллый идем. Әңгәмәдән соң тирән дигән сыйфатны да өстәдем үзенә. Оста куллы да икән әле.

:: Артист баласы артист була инде ул, дисәләр, күңелеңдә беренче нинди тойгы уяна?

– Мөгаен, елмаю уянадыр. Кеше тормышлары бер-берсенә охшамаган бит. Һәр гаилә үзенчә яши дигәндәй. Күп кенә артистлар да балаларын артист булмаска өнди. Чөнки безнең илдә артист тормышы җиңел түгел. Аның хезмәт хакы да кечкенә, ул үз вакытына да хуҗа була алмый. Сине эшкә теләсә кайсы вакытта чакырырга мөмкиннәр. Әйтик, кайсыдыр артист авырып китә, аның өчен уйнап торырга кирәк була, я репетиция вакыты үзгәрә. Менә мин үзем дә балама боларның барысын да тасвирлап күрсәтер идем дә аңа сайларга мөмкинлек бирер идем. Шәхсән миңа әни артист һөнәренең барлык ягын да тасвирлап бирде, әмма мин шушы һөнәрне сайладым. Миңа калса, кулымнан килгән һөнәрләр арасында иң яхшы башкарырдае – артист булу.

:: 3 яшьтән сәхнәгә чыккан баланың театр юлын сайлавы, бер караганда, табигый...

– Чыннан да, өч яшьтән сәхнәгә чыккач, бу инде артист булыр дип уйларга мөмкиндер. Ләкин мин табиб булырга хыялланган идем. Ә менә 17 яшемдә Камал театрында «Кара чикмән» спектаклен карагач, театрга барасым килде. Минем фикеремчә, ул Фәрит абыйның (Бикчәнтәев, Камал театрының баш режиссеры. – **Ред.**) иң яхшы спектакльләренең берсе. Ул миңа бик тәэсир итте һәм шушы дөньяның бер өлеше буласым килде. Ник дигәндә, театр миңа кечкенәдән табигый мохит, мөгаен, шушында үскәнгәдер дә инде (әнисе Раушания Фәйзуллина – Әлмәт театры артисты. – **Ред.**). Монда булу, эшләү, яшәү миңа авыр түгел, табигый, гадәти. Ә инде эш синеке түгел икән, интегергә кирәкми. Тормыш мизгел генә, эштән тәм табып эшләргә кирәк. Артист баласы артист һөнәрен исә табигатендә шул сәләт ятса гына сайлый торгандыр.

:: Үзеңне башка актрисалар белән чагыштыралармы?

– Күпчелек очракта мине чагыштырмыйлар, кем беләндер бутыйлар. Бик еш Нәфисә Хәйруллина белән бутыйлар иде. «Курчак туе» спектакле барганда, мине Камәр ролендә дип уйлаучылар да бар иде. Хәтта, ул спектакльдә башка рольне башкарам дигәч, туганнарым арасында алдады дип упкәләүчеләр дә булды. Җырчы Зәринә Вилданова белән дә бутаганнары бар. Чагыштырганнарын күргәнем, сизгәнем юк. Үзем исә беркемне дә беркем белән дә чагыштырмыйм, һәр кешенең уникаль икәненә ышанам. Кайчак тышкы кыяфәтләрдә охшашлык булса да, күңелләр төрле бит. Тормышка караш, яшәү рәвеше, эш алымнары һәрберебезнең кабатланмас. Шуңа чагыштыруны ахмаклык дип санарга да мөмкиндер әле.

:: Ләйсән – максатчан, эзләнүчән, иң тырыш артист, диләр синең хакта. Театр дип яну ул – холкыңның бер сыйфатымы? Әгәр театрны ярату уты сүрелә башласа, аны ничек дөрләтеп җибәрергә?

– Тырыш дип әйтә алмыйм үземне. Әйтәм бит интегеп яшәргә яратмыйм, интеккән кешеләрне, үзләрен корбан итүчеләрне дә яратмыйм һәм моны җүләрлек дип саныйм. Минемчә, эшең сиңа ошый һәм син аны интекмичә эшлисең икән, син янасың, эзләнәсең инде. Театр дип яну – холык сыйфаты да түгел ул, фәкать дөрес урында булуның нәтиҗәсе. Театрны ярату исә гомерлек була алмый. Ул ир белән хатын мөнәсәбәте кебек. Гаиләдә дә бит гел яратышып кына яшәмиләр, төрле хәлләр була. Театрда да шулай: ярату сүрелә, яңадан кабына. Иҗат юк икән, теләсә кайсы артист театрны сөйми башларга мөмкин. Ник дигәндә, артист, иҗаты туктамса, сүрелә, интегә башлый. Минемчә, артистның иң зур бәхете – иҗат булу, төрле режиссерлар белән эшләп карау, кызыклы әсәрләр, проектлар, лабораторияләрдә катнашу, нииндидер яңа коралда эшләргә өйрәнү. Болар барысы да театрны яратуны дөрләтеп җибәрә. Моннан тыш китап белән дус булырга һәм тормыш күзаллавын төрләндерү өчен сәяхәт итәргә кирәк. Яңа мәдәният, яңа кешеләр белән аралашу һичшиксез баета. Шул ук вакытта башка театрларның спектакльләре белән дә танышып барырга кирәк. Димәк, беренче чиратта тырышлык түгел, кызыксыну, дөньяга ачык булу һәм төрле карашларны кабул итә белү кирәк.

:: Шәхсән миңа рольләрең арасында «Миркәй белән Айсылу»дагы ролең бик тәэсирле булды. Айсылу аша синең үз хис-кичерешләрең дә ургып чыкты бугай. Әллә ялгышаммы?

– «Миркәй белән Айсылу»ның көче – кешеләргә үз күңелләрендәге хәлләрне аңларга мөмкинлек бирүендәдер. Без барыбыз да җәмгыять алдында көчсез. Ул сине изәргә, юкка чыгарырга мөмкин. Һәр кешедә менә шуннан курку ята. Шул ук вакытта сәхнәдәге мәхәббәткә дә һәр кеше реакция бирә, үз башыннан кичергәннәр белән чагыштыра.

> Мин үзем бала чакта да, үсмер чакта да җәмгыятьнең тискәре көчен тойдым. Әлбәттә инде, монда тулаем җәмгыять турында түгел, кечкенә төркемнәр белән бәрелешләр турында сүз бара. һәм гаепсездән гаепле булып калганым да булды. Ләкин мин аны бик шәп сабак итеп кабул иттем һәм алга таба кеше турында, җәмгыять фикеренә таянмыйча, үз башым белән фикер йөртергә өйрәндем.

«Миркәй белән Айсылу»да ничек елаганымны һәм нәрсәдән елаганымны әйтсәм, сез көләчәксез. Ул спектакльдә минем гомерем гел шушылай булырмы икән, тормышым шушында гына, беркая да китмичә, үзгәрешләрсез калырмы икән дип елыйм. Нигәдер шул уй елата, күңелемне төшерә. Бер урында калу, тормышның туктап калуы борчый.

:: Иң сокландырганы, мөгаен, «Хуш, авылым»дагы әверелешләреңдер. Авыл хатыннары холкын озак өйрәндеңме? Гомумән, рольгә әзерлек нәрсәдән башлана, ничек бара?

– Әлеге документаль спектакльнең беренче өлешендә мин әбиемне уйныйм. Һәр елны җәй айларында аның белән тора идем, аны бик яхшы беләм кебек иде. Спектакль өчен интервью алганда үзем өчен яңа әйберләр ачтым. Бу күңелемне тагын да баетты. Хәзер инде әниемнең әнисенең, гомумән, нәселнең нинди булуын күбрәк аңладым. Үз нәселеңне белү сиңа көч өсти. Тамырларыңны белсәң, ничек энергияң артмасын ди инде?! Урысча шундый термин да бар: «заземление». Бу – аяк астындагы җирне тоеп яшәүдер, мөгаен. Әби белән сөйләшкәннән соң мине борчыган сорауларның нәселемдә булганлыгын аңладым. Ә башка образларга килгәндә, әйтик, клуб мөдире яки банан сатып алучы – алар да тормыштан. Балачакта үзем дә кивины черегән лимон дип кабул иткән идем. Банан күргән кешенең нәрсә икәнен белмәвен аңлау читен булмады. Колумбиягә баргач, башка төрле бананнар күргәч, тагын аптырап калдым. Анда зур-зур бананнарны – плантанны пешереп кенә ашап була. Безнең спектакльдә пешкән банан тәмсез булса, Колумбиядә пешмәгәнен ашасаң, агуланырга мөмкин. Клуб мөдире исә – һәр авылда була торган позитив апа образы. Үзем Арча районының Симетбаш авылына бик еш кайткач, авыл кешеләре белән аралашкач, аларны аңлыйм. Өч ай шунда яшәгәч, гомумән, авыл кызына әйләнәм. Авыл да – көч бирүче чыганак. Бу җәйне шундый фикергә килдем әле: безгә хәзер гади тормышка ризалашу шулкадәр авыр икән. Социаль челтәрләрдә матур тормышларны күргәч, гади тормыш канәгатьләндерми башлый. Ә бу җәйдә мин беренче тапкыр гади тормышка риза булдым. 35 ел яшәү дәверемдә... Һәм миңа шундый тыныч һәм рәхәт иде. Каядыр чабарга, кемгәдер нәрсәдер исбат итәргә кирәкми, күңел чайпалмый.

«Хуш, авылым»да рольгә әзерлек төрле кешеләрдән интервью алудан башланды. Текст эше тәмамлангач, образлар өстендә эшләдек. Хәтта образга кергән артисттан интервьюлар да алып карадык. Ул сорауларга образда

Блиц-сораштыру

– Иң зур теләгең?
– Бар дөнья дуслашсын иде.
– Соңгы укыган китабың?
– Элиф Шафакның «Сорок правил любви» китабы.
– Үзеңнең иң кадерле ролең?
– Алар берничә. Шекспир әсәре буенча куелган «Чамасына күрә чарасы» спектаклендә – Изабелла, «Җәйнең бер көне»ндә – яшь хатын, «Миркәй белән Айсылу»да – Айсылу рольләре.
– Сине ачкан режиссер ул –
– яңача ачкан режиссер – Айдар Җаббаров.

килеш җавап бирергә кирәк иде. Айдар Җаббаров әнә шундый кызыклы алымнар белән эшләде.

:: Сүз уңаеннан, Камал театры «Турандыг»ы белән Тинчурин театры «Турандыг»ы ни дәрәҗәдә аерыла?
– Камал театры «Турандыг»ын Кытай режиссеры Кытай операсына охшатып куйды. Безнең тәрҗемәне Рүзәл Мөхәммәтшин эшләде, ул шигъри иде. Тинчурин тексты исә проза рәвешендә язылган. Тинчурин театры постановкасында заманча киемнәр, алымнар ошады. Бик кыска вакыт аралыгында куелуы сиземли дә хәтта. Яшьләрнең органикасы кимчелекләрне шулкадәр каплады, ул күренми дә башлады. Иң ошаганы шул булгандыр. Ике постановка бик төрле, икесе дә кызыклы.

:: Турандык ролен башкарыр идеңме?
– Юк, башкармас идем. Минем үземнең ролем – Гаделмәләк тә бик кызыклы иде.

:: Әгәр беркөн театр эшенә нокта куям дип ниятләсәң, нинди юнәлеш сайлар идең?
– Белмим. Мин төрле юнәлешләрдә эшләп карыйм. Кемнәргәдер актерлык осталыгыннан дәресләр бирәм, тегеп, чигеп карыйм, әмма әлегә киләчәктә шуларның кайсы беләндер шөгыльләнермен дип әйтә алмыйм. Шулай да кул эше – күңелгә иң якын шөгыльләрнең берсе. Хәзерге вакытта күн белән эшләргә өйрәнәм, «Казан җөе»н үзләштердем. Бәлки ул юнәлештән китеп булыр. Телләр өйрәнүгә дә хирыслыгым бар.

:: Ә чигү, тегү осталыгына кайдан өйрәндең?
– Мин тегә белмим. Чигә һәм бәйли беләм. Күн белән эшләүне дә чигүгә кертәм. Бу осталыкка әнием өйрәтте. Әбием, апалар барысы да чиккәннәр, бәйләгәннәр, оста шәл бәйләүчеләр булганнар. Әби бу һөнәрен – кызларына, кызлары балаларына тапшырган. Әбиемнең беренче баласы Фоадия апа бик күп чигә һәм «Зәңгәр шәл» спектакленә чыбылдык чиккәндә ул ярдәм итте.

:: Чигү дигәннән, спектакльләргә алъяпкычлар, яулыклар чигеп бирәсең дип ишеттем.
– «Дон Жуан» спектаклендә Люция Хәмитова образы өчен пальто, Хәлим абый Җәләйгә башлык бәйләгән идем. «Зәңгәр шәл»гә сигез метрлы чыбылдык, 13 яулык, 11 алъяпкыч чиктем. Әлегә кадәр алъяпкычларны яңартып торам.

:: Ләйсән, авыр рольдән соң көчне ничек тупларга?
– Авырлык һәм начар энергияне су белән юып төшерергә өйрәндем. Су тынгысыз уйларны да алып китә бит ул. Аннан соң тәмләп чәй эчәргә, вакытында ятып йокларга, ә иң мөһиме – үзеңне яратырга кирәк. Теләсә кайсы стрессны шулай гына җиңеп була.

:: Менә хәзер дә һәрберебез нindидер бик авыр роль башкара кебек. Дөньяга аек караштa калу өчен нинди киңәшләр бирер идең?
– Хәзер иң мөһиме – кешелекле булып калырга кирәк. Ярдәмгә мохтаҗларга булдыра алганча ярдәм итү зарур. Үзеңне дә онытмаска, физик сәламәтлегеңне дә, психик сәламәтлегеңне дә кайгыртырга кирәк. Авырып китсәң, беркемгә дә ярдәм итә алмаячаксың бит. Әгәр вазгыятьне үзгәртә алмыйсың икән, аның турында көне-төне уйламаска кирәк. Үзеңнең кулыңнан килгән кадәресе турында гына уйларга, шул юнәлештә эш алып барырга мөмкин. Паникага бирелмәскә кирәк. Күңелең төшә икән, телевизор карамау хәерле. Без барыбыз да – кешеләр. Һәм һәр кешенең гомере ул – Ходай бүләге. Шуны онытмаска, догалар укып, яхшылыкны сорарга, үз эченә бикләнмәскә кирәк дип уйлыйм. Барыбызга да аек акыл телим. Бусы инде кемнәр белән аралашуга да бәйле.

:: Театрда киләчәгеңне ничек күрәсең?
– Бу хакта уйламаска тырышам. Бүген белән яшим.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

Табиб язмалары

Руфина ФӘТТАХОВА

«Күңел ачу»

СССР таркалды, илдә ыгы-зыгы башланды. Бөтен халык илдәге үзгәрешләр хакында гына сөйләшә. Телгә әллә нинди аңлашылмаган сүзләр килеп керде: ваучер, инфляция, приватизация, дефолт, девальвация һәм башкалар. Иң мөһиме – күнегелгән тормышның рәте китте: кибетләр бушап калды, эш хакы вакытында түләнми, базарларда азык-төлеккә якын килерлек түгел – кыйммәт. Кайбер предприятиеләрдә хезмәт хакын товарлата түли башлаганнар. Мәсәлән, бер совхозда хезмәт хакы урынына капчыклап резин галош өләшкәннәр, ди. Анысын безгә дәваланырга кергән бер агроном сөйләгән иде. Монысына да исем табылган – бартер дип атала ул.

Мин эшләгән ГИДУВта да (врачларның белемен күтәрү институты) үзгәрешләр башланды: үткән бер-ике ай өчен эш хакы түләнмәгән, әле генә үткәне өчен берничә процент бирәләр, тора-бара элеккесе гомумән каядыр югала. Галимнәр фән белән шөгыльләнүләрен ташлап, больницаларда гади врач булып эшли башладылар, теоретик кафедрадагыларның күбесе бөтенләй башка өлкәгә – сату-алу эшенә китеп көн күрә башладылар. Мин дә, укыту эшендә ярты ставкага калып, үзебезнең укыту базасы саналган Каменкада врач булып эшли башладым. Күп тә үтмәде, мине диагностика бүлегенең мөдире итеп билгеләделәр. Мөдир кеше авыруга диагноз кую һәм аны дәвалау белән генә чикләнми, аның башка төрле эшләре дә җитәрлек.

Шулай бер көнне иртәнге рапортта төнге медсестра бер авыруның магнитофоны югалуы турында әйтте, теге авыру кемгәдер: «Магнитофон табылмаса, үтерәм», – дип янаган, имеш.

– Мондый эшләр белән шөгыльләнү минем вазыйфага керми, милиция чакыртыгыз, – дидем мин бүлекнең өлкән сестрасына.

Үзем мондый тәкъдимнән үтәлмәячәген белеп торам, чөнки, сәбәбен әйткәч, милиция я бөтенләй килми, яисә, берәрсе тузына башласа, алып китәләр дә, бер-ике сәгатьтән авыру кайтып та керә.

Рапорт тәмамланды, мин гадәттәгечә көндәлек эшемне планлаштыра башладым. Шулвакыт төнге медсестра кире керде һәм бик зур сер әйткән кебек:

– Руфина Мәгсумовна, магнитофон палатада икән, миңа аны шыпырт кына бер авыру әйтте, хәзер беркемне дә палатадан чыгармыйлар, сезне көтәләр, – диде.

Бу кыз бездә яңарак кына эшли башлаган иде, кыяфәте бик куркынган кебек күренде.

– Бик әйбәт, өлкән сестра белән керегез дә эзләгез, – дидем.

– Мин куркам, үтереш булса, суд юлыннан кайтып кермәссең, – диде сестра, калтыранып. – Аннан соң, минем эш сәгатем бетте, мин китәм, – дип өстәде.

– Ярый, кит алайса, – дидем.

Бу палатада магнитофон булганын да, аның кемнеке икәнен дә белә идем мин. Бөтен палатаны үз кулында тотучы рецидивист икәнлеге дә бөтен персоналга билгеле иде. Ләкин озак кына күзәтүемә карамастан, аның тәртип бозганын күрергә туры килмәде: персонал белән итагатьле, даруын вакытында эчә, вакытында йокларга ята, музыкасын да башка авыруларга комачауламыйча гына тыңлый. Күрәсең, тагын үзләренчә күңел ачарга уйлаганнардыр. Үземә дә кызык булып китте: кая яшерәсең инде ул магнитофонны – инә түгел ич ул. Палаталардагы бөтен җиһаз: караватъ, тумбочка, суыткыч... Зуррак палаталарда бер-ике табуретка булырга мөмкин.

Кердек без өлкән сестра белән 9 кеше яткан зур палатага. Мин тыныч кына:

– Сезнең палатада әйбер югалган диделәр, кем нәрсә югалтты? – дип сорадым, кемнең нәрсә югалтканын белсәм дә.

– Минем магнитофон югалды, кичтән бар иде, бөтен кеше күрде, иртәнгә юкка чыккан, – диде «югалтучы».

– Син урлаган кешене үтерәм дип янагансың диделәр, дөресме?

– Башку оторву! – ди бу.

– Димәк, кем урлаганын беләсең?

– Шикләнгән кешем бар, ләкин магнитофон әле табылмады...

– Димәк, магнитофон табылу белән, урлаган кешенең башын өзеп ыргытачаксың?

Тынлык. Кемдер түземәде, көлеп үк җибәрде. Шул вакыт безгә күптән түгел генә дәваланырга кергән яшь егеткә күзем төште. Күзләре борчулы, бите агарынган. Беренче ел эшләмим – палатада ниндидер конфликт чыккан яисә авырулар бәхәсләшкәннәр. Магнитофон «югалткан» авыруның күзенә туп-туры карап:

– Сиңа үз башыңны үзеңә өзү кыенрак булмас микән? – дидем дә чыктым да киттем палатадан.

Соңрак өлкән сестра миңа кереп, хәлнең ничек булып беткәнен сөйләде. Аны бу уенның азагы ни белән беткәнен беләсе килү тоткарлаган иде бугай. Тентегәндә теге куркынган авыруның койкасында җәймәсе булмавы ачыкланган. Сораштыра башлагач, тегесе елап ук җибәргән, чөнки магнитофонның кая киткәнен чыннан да белмәгән, антлар иткән. Магнитофонны шул җәймәгә төрәп, суыткычның түндыра торган бүлегенә тыгып куйганнар икән. Сестра, артык исе китмичә генә:

– Акчага бәхәсләшкәннәрдер, – дип куйды.

Ул көнне мин бу палатага башка кермәдем. Икенче көнне иртүк магнитофон хуҗасы кереп, кичәге хәлләр өчен гафу үтенде.

– Сезнең спектакльләрдә уйнарга да минем вакытым юк, – дидем коры гына.

– Доктор, зинһар, ачуланмагыз, мин сезне катнаштырырга гомумән уйламаган идем! – ди бу ихластан.

Мин ирексездән көлеп җибәрдем.

– Күңелсез бит, доктор. Айлар буе бер эшсез аунап ятасың... Аннан соң... теге маңканы акылга утыртасы да бар иде... – дип куйды.

– Менә нәрсә, режиссер иптәш, тагын бер мәртәбә төрмә сценарийлары буенча күңел ачарга уйласаң, мин сине больницадан чыгарып җибәрәм. Аңладыңмы?!

– Сәбәбе юк, мин бит тәртип бозмыйм...

– Табармын сәбәбен, – дидем.

– Аңладым, доктор, башка кабатланмас, безнең палатада тәртип бозучы булмас, ышаныгыз миңа, – диде. – Тереләсем килә минем, тормышымны өр-яңадан башлыйсым килә.

Чыннан да, бу авыру больницадан чыгып киткәнче, әлеге палатада тәртип бозучы кеше булмады.

Ришвәт

Яшь чактагы вакыйгалар хәтердә бүгенгедәй саклана икән. Институтны тәмамлап, беренче ел эшләп йөргән вакытлар. Яңа бинага күченгәч (1964 елны диспансерны Патрис Лумумба урамындагы бинага күчерделәр. Әлеге бина узган гасырның 40 нчы елларында салынган, башта мәктәп, аннары сырхауханә булып хезмәт иткән. 1964 елдан 2011 елга кадәр биредә туберкулез диспансеры булды. Былтыр бинаны сүттеләр. – **Ред.**), мине никтер хирургия бүлегеннән хроник авырулар ята торган бүлеккә күчерделәр. Бу бүлектә бик авыр хәлдәгеләр ята торган дүрт кешелек палата бар иде. Дөресен генә әйткәндә, бу авырулар әҗәл көтәләр иде инде. Барысында да авыруның иң йогышлы чоры. Мондый авырулар гадәттә көйсезләнәләр, аларны юату, өметләндерү бик авыр, табибка гаять түземле булырга туры килә. Палатадагы бер авыру үлеп китсә, икенчесенә бу нык тәэсир итә, нәтиҗәдә тегенең хәле тагын да авырая. Менә шул 4 кешелек палатада Садыйкова фамилияле урта яшьләрдәге бер апа ята иде. Үзе ягымлы, үз-үзен түгел, күбрәк мине кызгана иде бу. Берничә мәртәбә: «И, балакаем, үпкә чире йоктырасың бит яшь-яшь килеш, кит син моннан», – дип әйткәне дә булды. Хәтеремдә менә шул Садыйкова апага бәйле бер-ике вакыйга уелып калган.

Бервакыт (1964 ел бу) баш табибыбыз Мәскәүдә фтизиатрлар съездында булып кайтты. Кайтканның икенче көнендә, бөтен табибларны җыеп, җыелыш үткәрде. Дөресрәге, җыелыш булмады ул, табибларга съезд карарлары буенча курсәтмә бирү булды. Моннан соң бөтен Җир шарында гамәлдә булган, 100 ел дәвамында уңышлы гына кулланылган ясалма пневмоторакс (дарулардан тыш, үпкәгә механик ысул белән дә тәэсир итү. – **Ред.**) дип аталган дәвалау методын бүтән кулланмаска. Бөтен авыруларны, яшенә, җенесенә, хәлләренә карамастан, бер үк төрле итеп дәвалый башларга. Һәрберсенә бертөрле үк дозада 3 төрле дару бирергә.

Садыйкова апаның авырлыгы, күп булса, 40 кг булгандыр. Аңа даруны артык күп күләмдә бирергә ярамый. Әмма Мәскәү боерыгы булгач, берни эшләп булмый. Стрептомицин дигән даруны, кушылганча, 1 грамм итеп яздым. Бер укол гына эшләделәр моңа, йөрәк кагудан, башы әйләнүдән үлә язды. Шунда ук дозаны киметтем. Икенче көнне минe баш врач чакыртып алды.

Дәвамы бар >

МИН НИ ӨЧЕН КЫШНЫ ЯРАТАМ

– Кызым, синең иң яраткан ел фасылың нинди?
– Кыш.
– Димәк, көздән соң синең иң яраткан ел фасылың киләчәк.
– Әйе.
– Көтәсеңме аны?
– Әйе.
– Ә ни өчен син кышны яратасың?
– Чөнки кыш көне берәүне дә үтерәсе юк.
– Үтерәсе??? Ничек инде? Ә җәй көне үтерәсе бармы?
– Әйе. Черки һәм чебеннәрне.

Әз-мәз мәзәк

***

– Черри помидорларыгыз бигрәк ачы булган быел.
– Редис ул.

***

Синең алда бөтен ишекләр дә ябылса, шуны бел: суыткыч ишеген һәрвакыт ачып була, әле эчендә уты да яна!

***

– Сезнең компаниядә ничә кеше эшли?
– Яртысы.

***

Өйләнмәгәннәр өчен лайфхак. Хатынны туй күлмәге сатучы игъланы аша табарга була. Туй күлмәге сата икән, димәк, ул аерылган. Сиңа якын районнан табарга була. Һәм кирәкле размерлыны.

***

Әгәр дә уңыш сиңа арты белән борылды икән, димәк, ул сиңа ышана!

***

Ябыгырга кирәк икәнен Лилия шунда гына аңлады – ялгыш кына капкачы ачык люкка баскач, ул аның эченә төшеп китмәде.

Уены-чыны бергә

Дөрес түгел!

Стоматолог: «Сез тешегезне дөрес чистартмыйсыз».
Отоларинголог: «Сез колакларыгызны дөрес чистартмыйсыз».
Дерматолог: «Сез дөрес юынмыйсыз».
Гастроэнтеролог: «Сез дөрес ашамыйсыз».
Психолог: «Сез дөрес уйламыйсыз».
Терапевт: «Сез дөрес суламыйсыз».
Туганнар: «Сез дөрес яшәмисез».

Сканворд җаваплары

Горизонталь: әшнәлек, икенде, Лика, Ли, Токио, Луара, президент, Рабле, бура, Ржев, пармезан, камка, Тараз, зам, так, Ола, әби, Вайкуле, көрән, до, аквапарк, ирдәүкә, исе, әзи, ара, шериф, әрем, Нәҗип, Флүн.

Вертикаль: таракан, Ди, Ор, кабымлык, өмә, оператор, Җәлил, Әркәшә, киребеткән, әзер, иннек, Ва, иренү, Надир, Раил, имән, Клод, па, Асаф, ел, Азов, кер, СКА, Илнар, Ла, Анапа, ут, Айдар, без, Рауза, умач, Рамил, хан, елкы.



Беләсең килсә...

1 Ренат Ибраһимов нинди тавыш иясе иде?
а) тенор;
б) баритон;
в) бас.

2 Эрзә (эрзя) теле – бу милләт сөйләшүче ике телнең берсе:
а) мордва;
б) чуаш;
в) мари.

3 Язучы Заһид Мәхмүдинең улы телевидениедә эшли. Аның исеме:
а) Алмаз Гафиятов;
б) Фәнис Камал;
в) Марсель Мәхмүтов.

4 Скрипканың ничә кылы бар?
а) биш;
б) дүрт;
в) алты.

Җаваплар: 1. б); 2. а); 3. б); 4. б).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15890 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 343

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәрриренең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+